**ВАХИТ ГАЛИЕВ**

# БӘХЕТ ТАҢЫМ

**Шигырьләр**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2010

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Г18

**Галиев, В.В.**
Бәхет таңым : шигырьләр / Вахит Галиев ; кереш сүз авт. Л.Фаршатова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 143 б.
ISBN 978-5-298-01954-5
Вахит Галиев Татарстан Республикасының Мамадыш шәһәрендә яши. Әлеге җыентыкта аның лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланды.
УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01954-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2010
© Галиев В.В., 2010

**КӨЗЛӘРДӘ ДӘ ЯЗЛАР КАБАТЛАНА**

Бөек Ватан сугышы ветераны, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы, Шәйхи Маннур исемендәге әдәби бүләк иясе, Мамадыш шәһәренең мактаулы гражданины Вахит ага Галиев үз районында гына түгел, республикада да яхшы таныш. Язучылар, мәдәният-сәнгатькә катнашы булган кешеләр арасында аның туган авылы Иске Комазан янындагы умарталыгында ял итмәгән кеше бармы икән?! Ул җыйган гөмбә, җиләк, чикләвектән кемнәр генә авыз итмәгәндер?! Аларны үзе генә белгән аланнарда җырлый-җырлый җыярга ярата ул. Кайчак ул аланнарга кешеләрне дә алып барып бәйрәм ясый. Табигать кочагында матур, тату гомер итүче карчыгы Наилә апа пешереп биргән бәлештән авыз итә-итә шигырь укып, мәзәк сөйләп (шулкадәр күп белә һәм тәмләп сөйли ул аларны!), җырлашып (ул тавышы!) утыру үзе бер гомер бит ул.

Республикада иң беренчеләрдән булып туган авылы Иске Комазанда үз акчасына мәчет төзеткән, мулла алып кайтып, аңа йорт төзеп биргән, авылының зиратын тимер багана һәм челтәр белән әйләндереп алган кеше дә әле ул. Искиткеч мәгънәле әңгәмәдәш кенә түгел, дини яктан да гаҗәеп белемле үзе: теләсә нинди сорауга, Коръәннән булсын, хәдисләр китереп булсын йә булмаса үз тормыш тәҗрибәсеннән мисаллар китерә-китерә җавап бирә белә.

Тормыш юлы исә бик тә гыйбрәтле аның. Унсигезе дә тулар-тулмас 1944 елда армиягә алынып, яманаты белән тарихка кереп калган Суслонгер лагеренда хәрби әзерлек үтә ул. Аннары төрле частьларда хәрби хезмәттә була, полк мәктәбендә, хәрби училищеда укый. Фронтның үзегендә үк кайнамаса да, сугыш җимерекләрен күп күрергә, төзәтергә туры килә аңа. Авырый башлагач, бераз сихәтләнергә дип, өенә кайтарып җибәрәләр дә, яшьли сөйгән яры – Наиләсе белән кавышып яши генә башлауга, яшь кияүне тагын армиягә чакырып алалар. Гаилә белән частьтан частька күчеп йөреп арыгач, алар туган якларына кайтып төпләнәләр.

Сугыш арты еллары авылында яшәү өчен көрәш башлана. Наиләсе, бер-бер артлы туган балалары ач булмасын өчен, нинди генә эштә эшләми Вахит: такта яру мастеры да, бригадир, сатучы, клуб мөдире, авыл советы рәисе, партоешма җитәкчесе, Уразбахты авылында колхоз рәисе дә. Ул эшләгән елларда «8 Март» колхозының даны еракларга тарала. Уразбахты авылында дистәләгән йорт, ике катлы мәктәп, хуҗалык идарәсе, ашханә, кунакханә, дистәләгән терлекчелек биналары, Омар елгасы аша күпер төзелә. Лаеклы ялга чыгар алдыннан ул бер литр бензин табу да авыр булган, миллионнарча оешма, предприятиеләр берәр-икешәр ел хезмәт хакы түли алмаган елларда Мамадыш районының нефтебаза директоры булып эшли. Башкортстанга, тагын әллә кайларга үзе йөреп бензинын да юнәтә, коллективын да акчасыз яшәтми, меңгә бөтерелә, әмма таба, булдыра!

Пенсиягә чыккач та Вахит Вахит булып калды: өр-яңадан яши башлады. Районда беренчеләрдән булып үз бизнесын оештырып җибәрде. Яшь чагыннан ук куен дәфтәренә теркәп барган шигырьләрен берәм-берәм район, республика газеталарында бастырды, аннары китап итеп чыгарды. Унбер китабы дөнья күрде авыл чичәненең. Һәрберсендә һаман эзләнүчән күңел тибрәнүләре, кешеләрне, тормышны ярату, бергә гомер иткән Наиләсенә чиксез ихтирам.

Һәрвакыт шат, уенчак күңелле, тапкыр сүзле, җор телле, хатын-кызларны табигатьнең иң гүзәл һәм камил җимеше итеп саный торган ир белән яшәү җиңел булмагандыр тормыш юлдашы Наилә апага. 64 ел бергә гомер итү дәверендә сүзен дә ишеттергәннәрдер, гайбәтен дә олау-олау ташыганнардыр. Ә ул, ана арысландай, балаларын үз канаты астына җыеп, әтиләренең гаиләдәге дәрәҗәсенә энә очы кадәр дә тап төшертмичә, сабыр гына яши бирде. Шуның белән иренең, балаларының, нәселенең генә түгел, бөтен район халкының ихтирамын казанды. «Мондый үрнәк гаилә, Наилә апа кебек мондый да сабыр хатын тирә-юньдә башка юк», – ди алар хакында райондашлары.
Вахитныкылар! Аларның гаиләсен яратып, олылап, сокланып шулай бәялиләр. 9 балалы, 32 оныклы (7се оныгының балалары) бу зу-у-ур гаиләнең халык теленә яман яктан кергәне юк. Һәркайсы... табиб, шәфкать туташы, икътисадчы, укытучы, эшмәкәр буларак туган районы халкына хезмәт итә, берсе дә бәхет эзләп читкә китми. Ике килен, җиде кияү, икенче буын килен, кияү-балакайлар да шундыйлар, күз генә тимәсен! «Унынчы» балалары да бар әле аларның. Анысы – Татарстанның халык артисты, җырчы Миңгол Галиев.
Шунысы да гыйбрәтле: 83 яшьтә булуына карамастан, машинасын һаман да үзе иярли әле Вахит ага. Үзе әйтмешли, «кызлар»ны утыртып йөргәнгә шулай һаман яшь тә ул. Күп тапкырлар шаһит булганым бар, янында бер генә урыны буш булса да, ул юлаучы яныннан чаптырып узмый: туктап сораштыра, юл уңаен турылап, кирәк җиренә илтеп куя. «Рәхмәт җыям бит мин, – дип шаярта үзе. – Тормышымның шулай баруына шул рәхмәтләр булыша». Хәер, Вахит аганың күп гамәлләре рәхмәтле һәм соклангыч. Нәкъ шигырьләрендәгечә:

Яшәгәндә җырлап, янып яшим,
Төземәкче булып яңаны.
Кылган изге гамәлләре кала,
Җырларымда гомерем дәвамы.

*Люция Фаршатова,*
журналист, Татарстан Республикасының
атказанган мәдәният хезмәткәре

Бу китабымны, 64 ел бергә гомер итеп,
9 бала үстергән хатыным
Наилә Харис кызына багышлыйм

**ЯШӘҮ ЯМЕ СИНЕҢ БЕЛӘН**

Янган-көйгән чакта яшем чыкса,
Башым салам синең җилкәңә.
Юанычым, таянычым булгач,
Мин бурычлы гүзәл иркәмә.

Сусаганда суга омтылгандай
Тартылам мин сиңа, гүзәлем.
Сөялгәндә җилкәң сизмәгәндә,
Өзгәләнә минем үзәгем.

Кирәк түгел алтын, көмешләре,
Җаннарыма бәхет иңмәсә.
Нигә миңа яшәү, гомер үзе,
Яннарымда иркәм йөрмәсә?

Тормыш тәмле, яшәү ямьле икән,
Җан сөйгәнең булса янында.
Омтыласың алга, кирәк була бар да,
Күңел яши гомер язында.

**КҮҢЕЛ СИҢА ТАРТЫЛА**

Күңел сиңа таба канат җилпи һаман,
Бәхет тоеп синең янында.
Синнән алган назлар, иркә җылы хисләр
Яши, яшәр минем җанымда.

Тәндә каным кипсә, җаным тәннән китсә,
Синең исең калыр тәнемдә.

Әгәр йөрәк типсә, гомер дәвам итсә,
Мин яшәрмен синең тәмеңдә.

Пешкән җимеш булып, күз алдымда торып,
Буем җитмәгәндә өзәргә,
Үзәк өзелгәндә, яшьләр түгелгәндә,
Ходай ярдәм итсен түзәргә.

**ГОМЕРЕМ МИЗГЕЛЛӘРЕ**
Ерак калды безнең якты төннәр,
Йолдыз санап үткән сәгатьләр.
Өзде безнең яшьлек гомеребезне
Кинәт килгән ачы хәсрәтләр.
Бар кешелек канлы яшькә чумды,
Яшәү белән үлем тартышты.
Яшьлек назы янып утта көйде,
Бик аз яшьләр генә кавышты.
Пар канатлар насыйп булды безгә,
Бергә үттек озын юлларны.
Һәр мизгелен хәтер һаман саклый,
Искә алмый канлы елларны.
Үгез, сыер җигеп җир сөргәннәр,
Күз алдында ачка үлгәннәр,
Озын шинель киеп, ачка шешенеп,
Нарат урманында йөргәннәр.
Белорус, рус, немец, поляк белән
Елга суларында коендык.
Үзбәк «нан»ы белән туендык та
Нократка кайтып сыендык.
Еллар безне ерак алып китте
Яшьлектәге назлы таң белән.
Язлар, җәйләр үтте,
Алтын көзгә кердек
Гомерлеккә сөйгән яр белән.
Без кичергән көннәр һичбер кайчан
Алгы көннәремдә булмасын.
Тормыш газаплары мәхәббәтнең
Яшьлектәге ямен җуймасын.
**СӨЙГӘНЕМӘ**
Гомеремне сиңа багышладым,
Сиңа атап яздым җырымны.
Рәхмәт сиңа, миңа бәхет итеп
Биргәнеңә йөрәк җылыңны.

Күңелемдә минем чәчәкле яз,
Гөлләрендә сайрый сандугач.
Гомер гөлләремә су сипкән күк,
Күңелеңдә кошлар сайрагач.

Үрлеп үскән гөлләр саргаялар,
Салкын җилләр каршы искәндә.
Гомер чәчәкләрем мәңге шиңмәс,
Йөрәк җылың – минем хисләрдә.
**СУ СИБҮЧЕ СИН ИНДЕ**
Зирәк акылың миңа көч бирде,

Гомеремә яшәр ямь бирде.
Гөлләремне мәңге корытмаучы,
Су сибүче, бәгърем, син инде.
Аһ, корытма, зинһар, сип инде.

**СӨЮ – БӘХЕТ УЛ**
Яшьлегемдә бәхет көтә идем,
Була, диеп, алтын тәхеттә.
Сөйгәнемнең кайнар мәхәббәте
Алып килде мине бәхеткә.

Якынымның бер чәч бөртеген дә
Алыштырмас идем алтынга.
Алтын-көмеш эреп бетәр иде
Мәхәббәттә туган ялкында.

Нигә кирәк алтын, дөнья малы,
Бетсә җылың, туңса йөрәгең.
Дөнья малы күзгә күренерме,
Өзгәләнсә әгәр үзәгең.

Тик мәхәббәт җанга җылы бирә,
Алып килә олы бәхеткә.
Янып сөйсәң, тулы бәхет сизсәң,
Күзең төшми алтын тәхеткә.
**РӘХМӘТ СИҢА**
Мин бәхетле, яшәү көчем арта,
Синең җылың мине җылытса.
Йөрәк җылың, тәмең тәнне суытса.

Озак яшә, белеп, акыл белән,
Бик кадерле кеше син миңа.
Язлар булып шатлык биргән өчен,
Гел бурычлы калам мин сиңа.

**МИН БӘХЕТЛЕ**
**СИНЕҢ БЕЛӘН ГЕНӘ**
Кара, иркәм, минем күзләремә,
Мин дә карыйм күзем талганчы.
Мөмкин булса, күзләремне алмам
Соңгы тамчы каным тамганчы.

Йөзләреңдә кояш нуры күрәм,
Йөрәгемә дәва исләрең.
Син – якты нур гомер юлларымда,
Сине күрми торсам нишләрмен?!

Мин бәхетле синең белән генә,
Син дә рухы минем тәнемнең.
*** * ***
Кешеләр бит тәмләп чәй эчәләр,
Күзли минем күңел күзләрем.
Чәй теләгән саен чәй эчәргә,
Чәй бүләргә сине эзләрмен.

Бик кечкенә мизгел йөрәк ашый,
Күңел тәмең бетсә, урланса.
Бик куркыныч, авыр хәл ул, әгәр
Чәй эчәргә кешең булмаса.

Бакчабызда кош тавышы моңлы,
Кунган ботаклары корса да.
Яшә, бәгърем, яшә, бергәләшеп
Чәй эчәргә генә булса да.

**КАЙТ ТИЗРӘК**

Кайт тизрәк, җиләк бирәм,
Җиләктә йөри күңел.
Җиләкләр дә синнән башка
Ашарга тәмле түгел.

Бер-берләреңнең кадерен
Белмисең бергә чакта.
Син киткәч, көннәр сүрелде,
Бар уем синең хакта.

Җиләккә дип чыгып китәм,
Үзем гел сине көтәм.
Мөмкин булса, беркая да
Җибәрмәс идем бүтән.

**КАЙТАМ**

Кайтам, бәгърем, кайтам яннарыңа,
Сагыш сарды инде күңелем.
Еракларга киткәч төшенәм мин
Синсез яшәү мөмкин түгелен.

Күңел чәчәкләре тиз коела,
Җан җылыңнан китсәң еракка.
Сагыш борчыганда күңелеңне,
Ямь табылмый җырлап, елап та.

Мин бәхетле сине яратканга,
Сизеп яшәгәнгә син барын.
Син булдың, бар, мәңге булачаксың,
Җанга сулыш өргән тиң парым.

Гомер көзе барын уйландыра,
Югалтудан курка күңелем.
Пар канатлы булып яшәү генә
Озайтадыр кеше гомерен.

**ҮЗӘГЕНДӘ КҮҢЕЛНЕҢ**

Кан саугандай ярсып типте йөрәк,
Ватар сыман күкрәк читлеген.
Үзем түгел, шәүләм генә йөрде,
Син еракта калгач, сөеклем.

Яратуның көчен үлчәп булмый,
Көч юк аңа каршы торырлык.
Эх, көч булса икән һәр гаиләне
Аерылмастай итеп корырлык.

Йөрәкләре яна кошларның да,

Югалтсалар очар парларын.
Кешеләр бит аңсыз, җансыз кала,
Җуйса бермәл сөйгән ярларын.

Күп кичердем андый газапларны
Яшьлек елларында гомернең.
Сагышларда йөрткән сөйгән иркәм
Үзәгендә яши күңелнең.

**ЯШӘҮ БИРСЕН**
Син бит миңа Алла биргән бүләк,
Бәхет, шатлыкларга төрелгән.
Син – йолдызы минем гомеремнең,
Иң яктысы булып күренгән.

Алларыма минем кемдер килеп,
Фәрештәләр белән котыртса,
Сукмасам да, сүгеп куачакмын,
Тугры икәнемне онытма.

Чын ярату тугры, гадел була,
Мәхәббәт ул көчле үлемнән.
Сөйгән, сөелгәннәр – бәхетлеләр,
Бәхет табу, димәк, үзеңнән.

Язмышыма Алла сине биреп,
Гомеремне күмде гөлләргә.
Язларымны саклап, озак итеп
Яшәү бирсен алгы көннәргә.

**ГОМЕР КӨЗЕНДӘГЕ ЯЗ**
Табигый хәл, килер авыр бер көн,
Синме, минме алдан китәрбез.
Язлар кабатланмас, гомердә – көз,
Ялгыз калгач инде нишләрбез?

Кешеләргә хас бер күренеш ул –
Уйлар һаман борчый күңелне.
Юк шул, көчләр җитми (зур үкенеч)
Мәңгеләштерергә гомерне.

Чәчәкле яз сыман гүзәл яшьлек
Бик тә кыска булып тоела.
Дөньябызны күмгән мул яшеллек
Көзен сары булып коела.

Яшьлегемне уйлап сагынам да
Юләр чагым күреп үкенәм.
Әй бер Аллам, Сиңа табынам да,
Тигез картлык бир, дип үтенәм.

Һәрбер таңда сине күрү – шатлык,
Синең тавыш үзе наз бит ул.
Пар канатлы булып килгән картлык –

Гомер күзендәге яз бит ул.

Тагын озак гомер итсәк иде,
Йөресәк тә таеп, абынып.
Кайчан да бер китми булмас инде,
Китмә берүк мине калдырып.

**НАИЛӘМӘ**

Картаябыз, бәгърем, картаябыз,
Тик барыбер өзелеп сөям мин.
Гомер буе егет булалмадым,
Үз-үземне шуңа сүгәм мин.

Табигать ул үзенекен эшли,
Теләк кенә җитми кирәккә.
Юкса гомер буе тормышыңа
Ямьнәр бирү булды йөрәктә.

Син – кадерлем минем, иң көчлесе,
Яшәү бирдең миңа, ямь бирдең.
Мин бәхетле, гомер көземдә дә
Мәхәббәтнең тоям тәмен мин.

Мең-мең рәхмәт сиңа, фәрештәкәй,
Миңа яшәү, гомер биргәнгә.
Син янымда торсаң иде, бәгърем,
Үбә алсам иде үлгәндә.

**ШАТЛЫК ГОМЕР ӨСТИ КЕШЕГӘ**

Һәр таң безгә шатлык бирсен иде,
Шатлык гомер өсти кешегә.
Гомернең бит һәр минуты кыйммәт
Гомер иткән безнең ишегә.

Шөкер, бәгърем, илле өч ел икәү
Гомер юлын бергә үтәбез.
Шиңмәс өчен рухи куәт биреп,
Сиксән бишкә инде җитәбез.

Сиңа бәхет, шатлык бирү уе
Минем теләгемнең түрендә.
Син бәхетле хисләр кичерә алсаң,
Бәхетлегә саныйм үзем дә.

Авыр көннәр, авыр кичерешләр
Күп булдылар алар гомеремдә.
Яшьле булсалар да ул минутлар,
Канәгатьлек бүген күңелдә.

Зарланмыйбыз. Без язмыштан башка
Көч тапмабыз ерак китәргә.
И бер Аллам, насыйп кылсаң иде
Гомер көзен бергә үтәргә.

**ЗУР РӘХМӘТ АҢА**

Күңел шиңә, мендәр тарта башлый,
Рухи зәгыйфьләнә күңелең.

Рухланырга сәбәп, кешең булса,
Канатланып үтә гомерең.

Мин бәхетле: очып, янып яшим,
Җылы, иркә назга күмелеп.
Иртә таңнан күзләремне ачам,
Кояш нурларына үрелеп.

Мең-мең рәхмәт су сипкәне өчен,
Корытмаска теләп гөлемне.
Алла бәхет, саулык, гомер бирсен,
Зурлаганга гомер көземне.

**ГОМЕР ӨСТӘҮЧЕ**

Яз хәбәре, киткән кошлар кайта,
Дөньябызны күмәр гөл, чәчәк.
Бик бәхетле булыр идем, әгәр
Синең белән булса киләчәк.

Буш урын юк, бар да тигез тулган,
Нәфес дигәне дә туйгандыр.
Бәхет ишекләре бикле бугай,
Җаным үрсәләнү шуннандыр.

Алтын, көмеш, байлык бәхет бирми,
Күңелеңдә наз, ямь булмаса.
Нинди мәгънә соң, юлларыңда
Үрелергә гөлең тормаса.

Юлларымда өмет гөлем бит син,
Нур бирүче минем күңелгә.
Иркә назың, күңел язың белән
Көн өстисең алгы гомергә.

**БҮГЕН ДӘ МАЛАЙ**

Булсам иде искә алырдай,
Сагынып сөйләр бабай.
Ә хәзергә – кемнәргәдер
Йомышка йөрер малай.

Чутлашмыйлар йөрәк белән,
Саныйлармы сабыйга?
Әллә инде саныйлармы
Тулар-тулмас абыйга?

Минем яшькә яши алса
Ул сагынылган бабай,
Күрер идек без кайсыбыз
Борыны кипмәгән малай.

Яшьлекне сагынган сыман
Хыяллар һәм теләкләр,
Үталмастайны сагына
Юләр күңел, йөрәкләр.

Мин бабай булалмамын,
Артыгын узалмамын.
Теләгемдә булса да ул,
Бал-майда тоталмамын.

Беләм, бабай төскә матур,
Хатынга батыр булды.
Эш яшендә бик күп кырды,
Кулында маллар торды.
Андый көннәр минем үтте,
Кулдан маллар да китте.
Гомер көзе, санаулы көн –
Йомшар вакытлар җитте.

Нәфес яши, күңел тели,
Үреләм эзләп тәмнәр.
Бабай бабайлыгын итә,
Тыңлап бетерми тәннәр.

Мин гаепсез, күңел гадел—
Юкка ашыга йөрәк.
Аңлыйм, матур, гүзәлләргә
Бабайның яше кирәк.

Дөнья көчле яшьләр белән,
Алар бирә шатлыкны.
Яшьлек тәме өчен генә
Кимсетмәгез картлыкны.

**ҖИҢҮ СИЗӘМ**

Гомерем буе күңел түрләремдә
Хыял, хисләр, сүзләр йөрттем мин.
Хәрефләрдән тезеп хисләремне,
Гомер көзләремә илттем мин.

Зур калалар кора алмасам да,
Һәр хезмәтем булды уңышлы.
Гомер көзләремдә шатлык өчен,
Туган халкым, сиңа бурычлы.

Шигыремдә йөрәк җырларымны,
Хыял, хисләремне таратам.
Кешелеккә гел изгелек теләп,
Туган ягым, сине яратам.

**КАЙТ СИН**

Бакчаларда гөлләр чәчәк атты,
Хис, хыяллар минем гөлләрдә.
Шул гөлләргә карап юанамын,
Сине бик юксынган көннәрдә.

Чәчләремә чәчәкләрең кадыйм,
Исерәмен иснәп исләрен.
Шул чәчәкле гөлләр арасыннан
Күңел сине эзли кичләрен.

Тәрәзәмне килеп кагарсың дип

Көтеп үтә күпме көннәрем,
Иркә назлар көтеп, хыялланып,
Йокы алмый төнен күзләрем.

Кайт, бәгырем, кайт син яннарыма,
Миңа бәхет бирер таңнарда.
Алып кил син гомер язларымны,
Коендырып иркә назларга.
*** * ***
Якын дустым, бәйрәм бүләгенә
Сиңа диеп гөлләр эзләдем.
Корырлар да, гүзәллеге бетәр,
Ошатмассың диеп өзмәдем.

Күңелемдә көчле, изге хисләр,
Йөрәк каным ага сузылып.
Нинди ләззәт, назлар бирим сиңа,
Үбим генә мәллә суырып.

*** * ***
Бәйрәм миңа син булганда гына,
Син торганда гына янымда.
Салкын кышта син янымда булсаң,
Күңелемә килә язым да.

Чын күңелдән миңа язлар теләп,
Тәнне, җанны күмеп шау гөлгә.
Авырлыклар килгән чаклар бик күп –
Җиңел булыр, булсак гел бергә.
**ГӨЛЛӘР ЧӘЧИК**
Әкрен генә басып берәү килә,
Кояш нуры уйный йөзендә.
Көлемсерәп җиргә ләззәт чәчә,
Бәхет чаткылары күзендә.

Кара янган, сакал-мыек баскан,
Баш төзәтү өчен эзләнә.
Типсә тимер өзәр бу мескеннәр,
Юк, ошамый инде кемгә дә.

Гөлләр чәчик, эшләп ләззәт алыйк,
Мәрхәмәтле итеп күрсеннәр.
Ят җирләрдә сине күргән-белгән
Олы хөрмәт белән йөрсеннәр.

Кешеләрне ярат, матур күрен,
Шатлык чәчсен балкып гөлләрең.
Изгелекләр чәчсәң кешеләргә,
Бәхетле үтәр гомер көннәрең.
*** * ***
Сагындыра үткән яшьлек гомер,
Яшәп булмаса да хөрмәттә.
Ашаганнар безнең үлән булды,
Тәрбияне алдык хезмәттә.

Макталдык та, дөрес, кыйналдык та,
Түбән төштек, мендек югары.
Тигез юлдан, туры айга карап
Бәхет тапкан кеше юк әле.

Чиста акыл, тырыш хезмәт белән
Тормыш түрләренә менәләр.
Җиңел юлда бәхет эзләгәннәр
Ачлы-туклы яшәп үләләр.

Алла саулык, гадел акыл бирсен,
Тел байлыгы бирсен кирәктә.
Кешелеккә изге эз калдырсын,
Тузан бөртекләрен иләп тә.

**ЭЗЕМ КАЛСА ИДЕ ТАРИХТА**

Кара бүлмәләрдә кара мәче
Эзләп үтте яшьлек гомерем.
Өеп куйган бәхет таба алмадым,
Ни өчендер көтте күңелем.

Бармакларым белән җир казыдым,
Җәяү үттем урман, чүлләрне.
Берәмтекләп өйгәч бәхетемне,
Гаепләдем яшьлек – юләрне.

Чәчләремә инде кырау төште,
Сер бирәсе килми халыкка.
Мөмкин кадәр һаман хәрәкәттә,
Эзем калсын диеп тарихта.

Күңел күзем карый еракларга,
Бик киң итеп күрәм тормышны.
Күп тир түгеп тырышырга кирәк,
Алыр өчен мулдан уңышны.

Изгелекләр теләп җырлар язам,
Күргән чакта газиз күзләрем.
Мин бәхетле, йөрәк тынычлана,
Озак елга калса эзләрем.

**СИН БИТ БЕР ГЕНӘМ**

Мин һәрвакыт сиңа тартылам бит,
Көнбагышлар сыман, кояшка.
Гомер көзләремә җылы биргән
Син аем да миңа, кояш та.

Сандугачлар язын гына сайрый,
Көз җитешә икмәк, җимешләр.
Син – чишмәсе минем гомеремнең,
Тулып аксын өчен инешләр.

Язда, көздә, җәйдә, кышта гел син –
Чәчәк аткан гүзәл гөл генәм.
Каргаулардан куркам, син дә сагай,
Кыраулардан сагай, бер генәм.

**РӘНҖЕМӘ**
Тормыш дигәннәрең бик катлаулы,
Җайлап барып булмый барын да.
Син теләгән гөлне үстерә алмыйм,
Мин гаепле синең алдыңда.

Теләкләрем генә ихлас, изге,
Күңел җылым сиңа саклыймын.
Бәхет бирер өчен башым ватам,
Һич көчемнән килми – тапмыймын.

Рәнҗемә, рәнҗетмә мине, зинһар,
Фикерләрең белән ялгышма.
Мөмкин кадәр көчне терәсәк тә,
Ризалашмый булмый язмышка.
**СИН ҮЗЕҢ**
Бик вакытсыз төшкән кырау сыман,
Күңел гөлләремне корыттың.
Гомер язларыңны, иркә назларыңны
Мәңге саклыйм дидең, онытттың.

Уртак малны эт тә җыймый, диләр,
Уртаклаштың сагыш гамемне.
Югалттың ямемне, яшәргә тәмемне,
Керләдең син назлар тәнеңне.

Гөлбакчаңа тигәнәкләр үскәч,
Эзләмә башкадан гаепне.
Акланма да хәзер, зарланма да хәзер,
Син барсына үзең гаепле.
**ҮСТЕК ДИМИЛӘР**
Һәрбер нәрсәнең дә чиге була,
Тәгәрәмә, менгәч югары.
Дөньябызда барсын яулый алган
Көч тумаган, андый – юк әле.
Үзеңә син, бәлки, бик көчлесең,
Синнән көчлеләрне белмисең.
Күккә карап йолдыз эзлисең,
Борын астындагын күрмисең.
**ОНЫТТЫҢ**
Язмыш микән, ялгыш микән, белмим,
Гомер юлларыма юлыктың.
Язлар булып килгән хыялларны
Оныттың бит, бәгърем, оныттың.

Язлар үтә, кояшлы җәй җитә,
Мул уңышлы алтын көзе бар.
Дөнья яме, тормыш тәме бетә,
Онытылса көткән, сөйгән яр.

Хәтереңне яңарт һәм онытма!..
Чәчәкле яз килсен күңелгә.
Ихлас сөю – чын мәхәббәт кенә
Еллар өсти яшәр гомергә.

**САГЫНАМ**

Мин сагынам җәйге күл буйларын,
Икәү йөргән чакны бергәләп.
Мөмкин булса, янә барыр идем,
Түшем белән хәтта үрмәләп.

Күз алдымда йөртәм тау битләрен,
Җир җиләген җыйдык утырып.
Наратлыктан каен җиләген дә
Җыеп кайттык чиләк тутырып.

Хәтерлимен, эре, пешкәннәрен
Җыеп салдың минем чиләккә.
Ходай тагын насыйп кылса иде
Бергә йөрүләрне җиләккә.

**МИНЕМ ТЕЛӘК**

Сагыш, сагынулар авыру түгел,
Сау кешегә хас бу күренеш.
Җансызларда булмый борчылулар,
Җансызларда булмый үкенеч.

Минем күңел артык нечкә микән,
Тиз юксынам сөйгән кешемне.
Күңеле дә салкын таштыр, бәлки,
Сөя белмәс кеше ишенең.

Минем теләк – сөя-сөелә белү,
Кадерен белик иркә-назларның,
Кышын чәчәкләрен күреп яшик
Алда килер гөлле язларның.

**МИЗГЕЛЛӘР БАР**

Ак каеннар чуклы шәлен салды,
Шәрә калды шомырт, чияләр.
Тик кешеләр генә нәкъ киресен –
Калын бүрек, туннар кияләр.

Табигатьнең үз мизгелләре бар,
Җан иясен мизгел өйрәтә.
Табигатьнең таләпләре катгый,
Йә катыра, яки көйрәтә.

Аю кышны кар астында йоклый,
Куян тышкы төсен үзгәртә.
Шулай, дуслар, җирдә яшәү серен
Табигать ул үзе өйрәтә.

**ЭЗЛИМ ӘЛЕ**

Күңел тагын марҗа сорый бугай,
Нидер эзли явыз тәнемдә.
Өмет котә йөрәк эретерлек
Сөйгәнемнең тәне тәмен дә.

Күңелдә җыр язны искәртәме,
Оныткандай гомер көземне.
Изге хыялларым сүнмәс инде,
Мәңгелеккә йоммый күземне.

Хыял, өмет, бәлки, яшәтәдер,
Эзлим әле, эзлим тәмнәрне.
Эзләгәнне әгәр таба алсам,
Яшәртерләр сыман тәннәрне.

**ТИК СИН ГЕНӘ**

Тансыклатма мине тәннәреңә,
Кыйммәтлеген аңла теләкнең.
Мәгънәсен белми өзгәләнә,
Әйтер теле юк бит йөрәкнең.

Тик син генә, син бер генәм минем,
Тигезләүче яшәр дөньямны.
Йөрәк тәрәзәңне ачып ташла,
Ишетерсең ихлас догамны.

*** * ***

Таң алдыннан уянам мин,
Кошларның моңын тыңлап.
Юанам хезмәт булганда,
Яшьлек җырларын җырлап.

*** * ***

Яшьлекне юләр дисәк тә,
Кайтсын иде борылып.
Нинди ләззәт тояр идек,
Китсә дә бит орынып.

**ЯҢА ЕЛГА ӨМЕТ**

Һәр яңа ел безгә шатлык бирсен,
Тыныч тормыш, байлык килсен.
Һәр сабый да зур ышаныч белән
Алдагы көн матуррак була дисен.

Өмет бирә кешелеккә яшәү,
Өмет юллар эзли табарга.
Тормыш барсын өчен янарга,
Өмет таләп итә чабарга.

Яңа елда безгә саулык килсен,
Теләгәннәр алда илгә иңсен.
Һәрберебез шатлык җыеп йөрсен,
Сөелгәннәр өзелеп сөйсен.

**БӘЛКИ**

Ямьнәре күп, шөкер, тик ләззәт юк –
Китек кала күп чак күңелем.
Тәмен ала тәнем, белсәм дә бит,
Мин җырлардай көе түгелен.

Гүзәллеккә гел тартыла күңел,
Җырлап үтсәң иде гомерне.
Тик барыбер, әгәр шатлык бирсә,
Синекеме, әллә түгелме.

*** * ***

И бер Аллам, шатлык, куаныч бир,
Борчылулар килә күрмәсен.

Саулык булып, көен ятлый алсам,
Җырлармын да, бәлки, белмәссең.

**НЫК ТОТ, АКЫЛ**

Мөмкинлекләр гел чикләнгән инде,
Күңел генә ерак үрелә.
Биек таулар якын күренсә дә,
Менеп булмый, теләк сүрелә.

Мин әле дип канат җилпесәң дә,
Җирдән купмый аяк табаным.
Еласаң да кабат борып булмый
Чабып йөргән яшьлек заманын.

Тәрбиягә хезмәт кирәк сыман,
Рухи байлык кирәк картлыкка.
Гөлгә су сипкәндәй бәхет сизсәң,
Гомереңне күмә шатлыкка.

Бөгелмә син, күңел, каршы җилгә,
Белгән-күргән мескен димәсен.
Тормыш-диңгез ярга бәрмәсенгә,
Нык тот, акыл, диңгез көймәсен.

**АҢЛАША ТОРГАН ТҮГЕЛ**

Беләсеңме, җан фәрештәм,
Мин бит сиңа табынам,
Синең исеңә дә керми,
Мин өзелеп сагынам.

Күз алларымда гүзәлрәк,
Әллә бераз җүләрлек.
Чыгып йөгерәсе килә,
Хәлләр беткәч түзәрлек.

Кичкә керсәм, таңны көтәм,
Яктылык эзли күңел.
Тик үзем генә борчылам,
Аңлата торган түгел.

**ИРЛӘР БУРЫЧЫ**

Канәгатьлек, бәхет сизсен хатының,
Бу – ирләрнең изге бурычы.
Тормыш яме бозылмасын дисәң,
Артык салма ашка борычын.

Теләгәнчә булсын, теләк уят,
Тәм теләсәң кирәк күләмдә.
Үз парыңнан тәнең тәм алганда,
Үзең дә син уйла түләргә.

Үзең өчен генә тәм эзләсәң,
Уйламасаң парың турында,
Тәнең эретердәй назлы тәмнәр
Аз очрар гомер юлында.

**АЧКЫЧЫ БИТ ҮЗ КУЛЫҢДА**

Йолдызларга таба үрел,

Уянсын хыялларың.
Үтәм дип яшә тормышның
Иң биек кыяларын.

Сүнмә тәнеңә бәрелгән
Иң көчле җилләрдә дә.
Көйдермә уй-хыялыңны
Ут булган җирләрдә дә.

Өметеңне сакла берүк,
Үрел йолдыз тотарга.
Юк-бар белән пычранма,
Өйрән елан йотарга.

Киң күңелле, юмарт холык –
Изгелекнең билгесе.
Гайбәт сатып, борчак атмый
Кешеләрнең юньлесе.

Бәхет телим һәркемгә дә,
Уңыш хезмәт юлыңда.
Уйлап кара, бәхетеңнең
Ачкычы үз кулыңда.

**КИҢӘШ**

Агулы аш агулаган кебек,
Гаделсезлек бирә юньсезне.
Яхшы күрә, ишетә дип һич тә
Әйтмиләр бит чукрак, күзсезне.

Үрелмәгез бөек, олы хискә,
Мөмкинлеген дөрес күрмичә.
Килмәс димә бәхетсезлекләр дә,
Үлеп җир куенына кермичә.

Дөнья битен ачса, шөкер ит син,
Көтеп яшә артын ачасын.
Явыз ниятленең ала күрмә
Юкка биргән бүләк акчасын.

Гел рухланып яшә хезмәт белән,
Фикер сәләтеңне онытма.
Җиңел уйлап яки уйламыйча,
Бәхетсезлекләргә юлыкма.

Гаделсезлек күрсәң, читтән әйлән,
Юньсезлекләр күрми калсыннар.
Барма якын явыз, хәтәр утка,
Тик үзләре генә янсыннар.

Табигый хәл, чама югалганда,
Кыйбланы дөрес күрмиләр.
Һич онытма, явыз, гаделсезләр
Мендәренә ятып үлмиләр.

**ХУРГА КАЛМА**
Биек очтың, дустым, биек очтың,
Сызланырсың инде егылсаң.
Ярый да бит, сәләт көчең җитеп,
Кирәгенчә ерып чыгалсаң.

Дөнья хәлен белеп булмый, аңла,
Күкрәк сугып артык мактанма.
Дөрес бәяли күр сәләтеңне,
Караштыргалап йөр артыңа.

Киңәшем шул: акыллы бул, зинһар,
Тыйнак, уйлап башкар эшеңне.
Хурга калма, соң булуы мөмкин,
Дөрес бәяли күр көчеңне.
*** * ***
Сусап үткән яшьлек елларымда
Иҗат бакчам чәчәк атмады.
Йөрәк түрләренә төреп салган
Орлыклары кипми сакланды.

Гомер көзләремдә чәчәк атты
Иҗат көчем ярып һаваны.
Мин бәхетле – соңга кала язган
Җырларым бит гомерем дәвамы.

**ДАРУ ЯСА**
Бүген сине, иркәм, төштә күрдем,
Кочагыңда идең иреңнең.
Башың артка киткән, ыңгыраштың,
Юешләнгән иде иренең.

Мин ерактан барып карап тордым,
Син сыгылып татлы йокладың.
Уяндым да күңел борчылудан,
Таңны көтеп күзем йоммадым.

Мин ризамын, сине күрә алсам,
Саташсам да күреп төшемдә.
Үз чамамны белми сабыр итәм,
Ут булса да күкрәк эчендә.

Мөмкин кадәр су сибәргә тырыш,
Сәбәп ясый күрмә янарга.
Очрашканда назга күм син мине,
Дару яса йөрәк ярама.

**УЙЛАРГА КИРӘК**
Җаны барлар ял дип тормый,
Кайгырта якыннарын.
Авыз белән суын ташып,
Басалар ялкыннарын.

Бар кешеләр, дөньябызга
Килүчеләр сан өчен.
Аналарын оныталар
Тормыш куу, мал өчен.

Дөнья куып нәфес туймый,
Канәгать булу кирәк.
Сарыгың сау, бүре туйсын,
Уйларга кирәк, димәк.

*** * ***

Картая һәм туза тәннәр,
Теләмәсә дә күңел.
Беркемгә дә чикләнмичә
Бирелмәгән шул гомер.

Тәннәр картайганга инде,
Маңгайда тирән сырлар.
Картая шул, картаймый дип
Җырлансалар да җырлар.

Күңел генә өметләнә,
Һич туймый нәфес, теләк.
Күккә карый, йолдыз саный,
Ләззәт, наз сорый йөрәк.

**КӨРӘШ, КУРЫКМА!**

Һәрчак ак белән кара көрәшә,
Әйбәт белән гайбәт дус түгел.
Әкияттә түгел, тормышта да
Гел көрәштә үтә ул гомер.

Бер мизгелгә көрәш сүнеп торса,
Кабызырга бик күп көч кирәк.
Йөк туктаса, кузгатуы авыр,
Туктатмаска кирәк шул, димәк.

Көрәш кирәклеген аңламасаң,
Бәхетсезлек көтә, онытма.
Яшәү – көрәш, тырыш хезмәт сорый,
Авырлыклар тоеп курыкма.

Көрәшкәннәр тирән эз калдыра,
Гомер көзен күмеп шатлыкка.
Хезмәт диңгезендә бәхет яулап,
Бөгелми түз килгән картлыкка.

**КАБУЛ БУЛСЫН ТЕЛӘКЛӘР**

Кил, Яңа ел! Күп шатлыклар өстәп,
Муллык, бәхет төяп халыкка.
Тыныч хезмәт елы булып кына
Кереп калсын иде тарихка.

Күп өметләр сиңа багышлыйбыз,
Изге хисләр генә теләктә.
Җилләрең дә вакытында исеп,
Яңгырларың яусын кирәктә.
Кырларыңа Ходай уңыш бирсен,
Җиләк-җимеш уңсын бакчада.

Ил байлыгы җитсен һәммәбезгә,
Азайсын да кытлык акчага.

Яңа елда начар гадәтләрен
Онытсалар иде абыйлар.
Дөньябызга ямь, тәм, бәхет теләп,
Бик күп туса иде сабыйлар.

Гел гаделлек җирдә хөкем сөрсен,
Кабул булсын изге теләкләр.
Авырганнар өчен саулык бирсен,
Борчылусыз типсен йөрәкләр.
**ШИКЛӘНҮ**
Синсез үткән минутларны саныйм,
Горурланып карыйм язмышка.
Борчылулы үкенечтән куркып,
Барсын саныйм кайчак ялгышка.

Көзге җилләр тәннән хәлне ала,
Йомшарта да кулда тезгенне.
Азгын таем, дулап, текә ярдан
Бәрмәс микән аска үземне?

Булганнары бар да изге теләк,
Озайтырга гомер елларын.
Сәбәп булмаса иде назлар көтү
Өзелергә барыр юлларым.
**САГАЙ**
Әрәмдәшне керттең кичә көнгә,
Югалткансың миңа хисеңне.
Бик ялынып сорыйм, җиңел уйлап,
Пычратма минем исемне.

Күрмәсәм дә, күңел синең белән,
Тавышыңны көтә йөрәгем.
Ачуымнан тешләп өзәр идем,
Өзгәләнгән чакта үзәгем.

Үзең теләп килеп кердең бит син,
Йомшак җәеп күңел түремә.
Артык борчу мизгелләре сизсәң,
Үпкәлә син инде үзеңә.

Аңлыйсыңдыр, һаман гөлләр саклыйм
Синең өчен күңел түремдә.
Җүләр сатып, көз салкынын сизеп,
Яра ясый күрмә гомергә.
*** * ***
Сагыш эзләгәндәй ерак киттем,
Яратсам да туган ягымны.
Истәлекле, матур үткәрә алдым
Сезнең белән быел ялымны.

Күңелемдә сезгә изге хисләр,
Йөрәк җылым килә бирәсем.
Айлар, еллар оныттырмас сыман,

Килер әле сезне күрәсем.

Чәчәкләргә күмеп язлар килер,
Бутамасын инде ялгышлар.
Бүгенгене искә алу өчен,
Очратса иде язмышлар.

Сау булыгыз, дуслар, бәхилләшмик,
Очрашуны өмет сакласын.
Кайгы, исәп, бәхетсезлекләрдән
Алла безне үзе якласын.

Яшь каеннар безне көтсәләр дә,
Яшисе иде әле дөньяда.
Искә алыгыз, мин мәңгегә сезгә
Яшәрмен гел хәер-догада.

**СҮНМӘС КОЯШ**
Тышта буран, күзне ачып булмый,
Явызланып керә куенга.
Уйларымны буран күмә алмый,
Гел син генә минем уемда.

Күз алдыма килә күл буйлары,
Җәен чәчәк аткан болыннар.
Яшәү яме биреп сагындыра
Кояш сыман кайнар куеннар.

Тормыш булгач булды төрле чаклар,
Борчылулар, газап, ялгышлар.
Нәкъ табигать – язы, көзе килде,
Күп сынады безне язмышлар.

Хәзер шөкер, бар да җиңел үтте,
Нурлар чәчеп янсын йөзебез.
Иркәләшеп, назга чумып яшик,
Балкыганда гомер көзебез.
*** * ***
Күңел нечкә, юктан хәтер кала,
Канатлана гүзәл мизгелдә.
Йөрәк елый, яннан дуслар бизсә,
Баткан сыман чиксез диңгездә.

*** * ***
Күршедә бәлеш ашыйлар,
Мин иснәнәм урамда.
Чәй эчәргә кеше эзләп
Йөрим салкын буранда.

Чәй эчәргә пар табылыр,
Килсә тизрәк җәйләр.
Җәйне көтеп йөри-йөри
Суынмас микән чәйләр.

Бәлеш бетәр, кибектерер,
Ерак шул әле җәйләр.
Бәлештән тәмле тоелыр,
Бәлки, суынган чәйләр.
*** * ***
Хәерле юл теләп дога кылам,
Синең исемеңә табынып.
Белеп йөр син тугры йөрәгемнең
Яшәгәнен сине сагынып.

Юатырга, бәлки, җай табылмас
Сагыш нуры сеңгән йөзләрне.
Еллар безне еракларга илтер,
Тузан басар безнең эзләрне.

**БОРЧЫЛМАГЫЗ**
Борчылмагыз апа диеп,
Аның «яше» өендә.
Сезнең күңел булсын өчен
Бии бабай көенә.

Кадер-хөрмәт теләгәннәр
Кеше яшен санамый.
Сөя белә, яши бирә,
Гайбәтчегә карамый.

Картлык зәгыйфьлек түгел ул,
Сакласа яшәү көчен.
Бәлки, серле табышмактыр
Сөя белгәннәр өчен.

Апагыз картны тапкан дип
Борчылса йөрәгегез,
Уйлагыз, алар янында
Бар микән кирәгегез?
**ГАЕПЛӘМИМ**
Күңелемдә никтер караңгылык,
Ялгыштыммы әллә юлымда.
Авыр тойгыларым тәэсирендә
Сүрелгәндәй йөрәк җылым да.

Товар артса – бәяләре төшә,
Күп ашасаң, килә косасы.
Бик акыллы, үлчәү белгәннәрне
Чын йөрәктән килә кочасы.
Аңласам да, үлчәвемне бутап,
Тиешледән артык үрелдем.
Шуңа микән, күңел тартканнарга
Җүләр сыман булып күрендем.

Мин гаепле, артык чайпалдырсам,
Күп түгелә суым чиләктән.
Туйдырадыр тәмле аш-сулар да,
Артыграк булса кирәктән.

Туйдырганым өчен гафу ит син,
Борчыганмын күңел хисеңне.
Гаепләмим, әгәр авыр тоеп,
Онытсаң да минем исемне.

**РӘНҖЕДЕМ**

Бәйрәм бүген. Күпләр бәйрәм итә,
Бәйрәм түгел минем күңелдә.
Йөрәгемне кыса сагыш чире,
Сәбәпчесе – күңел түремдә.

Күңелеңә бәйрәм булсын өчен,
Җан теләгән кирәк яныңда.
Алар гына бәйрәм бирә ала,
Алып килә гомер языңа.

Көнем үтте. Уйлар ерак китте,
Рәнҗеп куйдым бәйрәм сизмәгәч.
Нишлисең бит, өмет иткәннәрем
Бәйрәм бирим әле димәгәч.

**ТӨШЕНМИСЕҢ**

Көннәр үткән саен, каты әчи
Син оеткы салган күңелем.
Гел каһәрләп, бар мизгелен җәллим
Синең янда үткән гомернең.
Вакыт үзе ныклап ышандырды
Дөреслеген минем күңелнең.
Син пычрак бер палачы идең
Көрәшләрдә үткән гомернең.
Онытмыйсың, ләкин әле һаман
Елан сыман ыслый теләгең.
Кешелеккә агу чәчмәк була
Явыз канлы усал йөрәгең.
Син гомергә аңга түбән булдың,
Бәяләми йөрдең үткәнне.
Гыж-гыж килеп, «мин» диясең килә,
Төшенмисең чамаң беткәнне.

**ГОМЕРЕМ ДӘВАМЫ**

Еллар үтә, барын алып китә,
Әзерләнми булмый китәргә.
Юллар эзлим, үзем киткәндә дә
Гомеремне дәвам итәргә.
Җырлар язам, җырлыйм исән чакта,
Дәваларга йөрәк ярамны.
Килер буын җырым җырлый алса,
Шул бит инде гомер дәвамы.
Изгелекне алга илтү өчен
Очып үтәм күпме араны.
Кешелеккә изге эзем калса,
Аларда бит гомерем дәвамы.

**ИЗГЕЛЕКЛӘР ТЕЛӘП**

Кагылмаган чөйләр, сала алмаган өйләр
Кемнән генә инде калмаган.
Җыеп булган барын, кешеләрнең малын

Алла сиңа гына язмаган.

Иркенлекне биргән, уйлап яшә, дигән,
Аер хәрам белән хәләлне.
Мал табарга тырыш, мескеннәргә булыш,
Һич онытма килер әҗәлне.

Чап син иртә торып, гөнаһыдан курык,
Гайбәт чәйнәп ләззәт эзләмә.
Үзеңнеке тулсын, башкага да булсын,
Кеше тормышыннан көнләмә.

Шөкерана кыл син, колагыңа керсен
Исән чакта азан авазы.
Акыл иясе бул, изгелекләр күп кыл,
Изгелекләр – гомер дәвамы.

Бәлки, ялгыштыр ул, әллә язмыштыр ул,
Үткәнеңә үкенеп карама.
Уйлап әйт сүзеңне һәм һич тә үзеңне
Оҗмах кошы итеп санама.

**КӨТӘМ**

Диңгез ярларында кибеккәндәй,
Ямь табалмый йөрим урамда.
Бергә чакта без канатлы идек,
Йөрсәк тә гел салкын буранда.

Өмет белән әле язны көтәм,
Яшәвемне күмеп гөлләргә.
Канатланып бергә очарбыз, дим,
Алла биргән алгы көннәргә.

Сандугачлар моңын тыңлар өчен
Чыгар идек парлап болынга.
Йөрәк җылым җәеп куяр идем
Син басардай һәрбер урынга.

Бел, кадерлем, йөрәк каным тама,
Бик сызланып үтә көннәрем.
Өзгәләнеп көтәм. Бергә булсак,
Чәчәк атар иде гөлләрем.

**КАЙТ ЯНЫМА**

Вулкан көче белән шартлар сыман
Уттай кызган тәндә йөрәгем.
Канат булса, күккә очар идем,
Өзгәләнгән чакта үзәгем.

Нигә киттең минем яннарымнан,
Тирән яра ясап күңелгә.
Синнән башка яшәү яме бетте,
Оныта алмам инде гомергә.

Язларымда чәчәк аткан иде,
Бозландылар инде гөлләрем.

Кояш батты, куе томан басты,
Караңгыда калды көннәрем.

Кайт яныма!..
Кояш балкыр иде күгемдә.
Яшәү ялкыннары янар иде
Сары баскан сүнгән йөземдә.
**НАСЫЙП БУЛСЫН**
Сиксән яшем тулган көнне таңда
Йомшак кына тоттым кулыңны.
Тойган сыман булдым тәнем белән
Миңа булган йөрәк җылыңны.

Рәхмәт сиңа, мәңге саклаганга
Сөю бирер гүзәл тойгыңны.
Насыйп кылсын иде синең кулда
Үткәрергә соңгы туемны.
**ЧӘЧӘКЛӘРЕҢ САКЛА**
Кунак гомер алда озын сыман,
Үткәч кенә кыска тоела.
Гаиләдә язлар салкын килсә,
Чәчәкләре яшьләй коела.

Бик яшьтән үк ни өчендер күңел
Яулык япканнарга тартылды.
Гомер көземдә дә шулар белән
Матур бизәк иттем ялымны.

Ягымлы сүз, изге назлы караш –
Көч өстәгән сыман йөрәккә.
Ял көннәре санаулыга микән,
Гел изгелек кенә теләктә.
**ШУНЫ ТЕЛИК**
Яшь чагында туган мәхәббәтне
Бик еш кына данлап сөйлиләр.
Беренчесе түгел, иң соңгысы
Кадерлерәк була, белмиләр.

Авызыңа салкын су тидереп,
Маңгаеңны сөртеп торсалар,
Нинди бәхет – соңгы сулышыңда
Җан сөйгәннәр янда булсалар.

Беренчесе һәм соңгысы булса,
Дәрәҗәсе – биек тауларда.
Пар канатлар булып картайсыннар
Яңа гаилә корган парлар да.
**БАРЫН УЙЛАП**
Яңа яуган кар өстеннән атлыйм,
Йөрәгемдә кайнар ялкыннар.
Күңелемдә яшәү көче биргән
Ак бәхеткә күмгән якыннар.

Табигатьнең саф һавасын сулыйм,
Шөкер итеп якты дөньяга.
Кешелеккә изгелекләр телим,

Сәбәп көтми хәер-догага.

Җир шарында бар да шома түгел,
Бик буталчык йөрер юллар да.
Ашыктыра никтер гомерләр дә,
Явыз сыман хәзер еллар да.

Барын аңлап тирән уйга чумам,
Сизми аяк мамык карларны.
Бер Ходаем насыйп итсә иде
Күрү көнен килер язларны.

**МИН САГЫНАМ**

Мин сагынам бергә үткән көнне,
Һәр мизгеле күңел түремдә.
Аерылгач, нидер югалткандай,
Сагыш томаннары күземдә.

Авыр сулап ыңгырашкан чаклар –
Алар аңсыз йөрәк авазы.
Беркемгә дә бирелмәсен иде
Аерылу – сагыш газабы.

**НАСЫЙП ИТСӘ ИДЕ**

Нинди бәхет, әгәр сөйгән халкың
Сиңа хөрмәт белән караса.
Якын дуслар, белгән, күргәннәрең
Уңган, изге итеп санаса.

Баскан саен шөкер итү кирәк,
Олы ышанычны акларга.
Бер Алладан акыл, тәүфыйк сорыйк,
Булган исемеңне сакларга.

Искәрергә кирәк, баскычлар күп,
Каршылыклар бик күп, чамасыз.
Сабырлыклар кирәк үтү өчен
Кисәк терәлгәндә чарасыз.

Бик катлаулы юллар, еллар алда,
Билгесезлек бик күп язмышта.
Тәкъдиребез насыйп итмәсәче
Бәхетсезлек бирер ялгышка.

**КҮЛМӘК БУЛ СИН**

Ир-хатыннар бер-берсенә күлмәк,
Бер-берләрен саклый күзләрдән.
Яшәгәндә булган кимчелектән,
Хак, нахаклы, ямьсез сүзләрдән.

Күлмәк бул син сөйгән иптәшеңә,
Сакла гаиләнең серләрен.
Матур күлмәк булып куандыр син
Якын дусларыңның күзләрен.

*** * ***

Кеше белми кеше хәлләрен,
Бик юксына сине тәннәрем.
Аерым үткән көнне җәлләдем,
Сагынып бергә яшәү тәмнәрен.

Канатлары сынган кошчык сыман,
Күңел боегуы бик яман.
Аерым яшәмәбез без һаман,
Канатларым үсәр берзаман.

Юк, кешеләр сагыш сизмәсен,
Аерылышу хәлен белмәсен.
Кайгы-хәсрәтләр күрмәсен,
Канатлансын, шиңеп йөрмәсен.

**ШИФАХАНӘДӘ**
Саф һавалы урман – нарат исе
Кама яры тавы өстендә,
Бер суласаң, мәңге шифа булыр
Тәнең өчен, җаның өчен дә.

Онытасың дөнья мәшәкатен,
Канатлана сүнгән күңелең.
Урман сукмагыннан атлаганда,
Озынаер кебек гомерең.
*** * ***
Калсын гомерем эзләре,
Керсен җырым тарихка.
Нинди бәхет, матур исем
Искә алынса халыкта.

Кем омтылмас изгелеккә,
Үрелмәс биеклеккә.
Барыбыз да аңлыйбыз бит,
Зур бәхет – изгелектә.

Явыз, яман холыклылар –
Кешелекнең чүпләре.
Андый бәхетсез затларның
Бик тар яшәү чикләре.

Алла акыл бирсен инде,
Сәләт бирсен уйларга,
Шатлык белән бәхет тоеп,
Барыйк соңгы туйларга.

**ХАТЫН-КЫЗЛАРГА**
Искә алам әни изгелеген,
Күпме борчу, газап күргәндер.
Хатын-кызга булган сөю, хөрмәт
Әни сөте белән кергәндер.

Хатын-кызга булган кадер-хөрмәт
Һаман әле күңел күгемдә.
Әниләргә, сезгә ихтирамым
Яши, яшәр йөрәк түремдә.

Аналардан башка тормыш юк ул,
Иркә-наз да хатын-кызларда.
Алар барда гына шигырь туа,

Көе туа ярсып җырларга.

**ЯЗМЫШТЫР**

Насыйп булмаса булмый ул,
Юлларыңа тау үсә.
Ашыйм дигән тәмле ашың
Кашыктан читкә төшә.

Көннәр буе су эзләдем,
Иреннәрем кибеккәч.
Елый яздым, тапкан суым
Учларымнан түгелгәч.

Язмыштыр шул, ни эшлисең,
Узып булмый язмыштан.
Аллам үзе саклый күрсен
Көтелмәгән ялгыштан.

*** * ***

Хөрмәтне кармалап булмый,
Кирәген йөрәк белә.
Хөрмәт белән игътибарны
Күрәсең йөрәк белән.

*** * ***

Рәхмәт, игътибар бирүче
Күңелем кошларына.
Йөрәк җылым бирер идем
Эчкерсез дусларыма.

**ЙОЛДЫЗЛАР СҮНМИЛӘР**

Күңел рухланып очкан чакта,
Йолдызлары яна күгемдә.
Милләтемнең йолдыз булып калган
Шәхесләре йөрәк түремдә.

Муса Җәлил ул – олы йолдыз,
Йолдызлар бит мәңге сүнмиләр.
Үз милләтен данга күмгән җаннар
Милләт белән яши, үлмиләр.

Милләтемә рухи байлык өстәп,
Күктә балкып калган нурлары.
Тарих битләрендә мәңге калыр
Милләтемнең батыр уллары.

**МАМАДЫШЫМ – ТУГАН ЯГЫМ**

Туган ягым урман, суларга бай,
Мул уңышлы иркен кырларым.
Хезмәт сөйгән халкым җырлап яши
Милләтемнең тынмас җырларын.

Мамадышым – туган-үскән калам,
Эзең тирән калган тарихта.
Нократ дулкыннары дуслык тели

Күпмилләтле безнең халыкка.

Тау битенә чәчкән гөлләр сыман
Нур сибәсең, калам, дөньяга.
Яшәү урының, изгелегең белән
Бай яшисең хәер-догага.

Яшә, калам, йолдызларга карап,
Дөнья күрсен якты нурыңны.
Җырласыннар барлык дөнья халкы
Изгелекләр чәчкән җырыңны.

*** * ***

*Рафаил Газизовка*
Изгелекләр теләп тәбрик итәм,
Гөлләр күмсен алгы юлыңны.
Күп милләтләр тыңлый алса иде
Каләмеңнән тамган җырыңны.

Күңелеңдә һәрчак язлар булсын,
Алла саулык бирсен үзеңә.
Дусларың да тыңлап соклансыннар
Фикергә бай ихлас сүзеңә.

Шатландыра Кытай каласыннан
Алып кайткан олы бүләгең.
Олы хөрмәт, янә зур бүләкләр,
Зур уңышлар сиңа теләгем.

Гомер баскычлары бик катлаулы,
Шөкер итик күргән һәр көнгә.
Ничек куанмыйсың, җил-давыллар аша
Алтмыш еллык үткән гомергә.

Гомер эзләреңдә гөлләр үсә,
Шатлык чәчеп безнең халыкка.
Килер буыннарга горурланыр
Исемең керде инде тарихка.

Тик борчылма, алтмыш – картлык диеп,
Ул яшьлеге олы картлыкның.
Насыйп булсын зурлап бәйрәм итү
Йөзгә җиткәч килгән шатлыкны.

**КЫЗГАНЫЧ**
Гаделсезлек ашый йөрәгемне,
Көчле буран борчый күңелне.
Өлгермәгән түрә кыланмышы
Кыскарта бит безнең гомерне.

Хуҗаларның артын ялый-ялый,
Гади кешеләргә төкереп,
Үгез сыман йөри кайбер юньсез,
Сөзәр сыман булып үкереп.

Гаделсезлек юк дип булмый, бар ул,

Аз булса да кара гомере.
Тотанаксыз «калай әтәчләр»нең
Чәчәк аталмый шул күңеле.

Бик кызганыч, кайчан мөмкинлек бар
Айкап талаучыга базарны.
Юкса күптән ташкапчыкта урын
Бик юксынып көтә аларны.

**ЧИЛӘК КИРӘК**
Нәфес әйбәт, хәлем начар,
Тора алмыйм урыннан.
Күзем яшьле, чиләк кирәк
Аккан суга борыннан.

**ВАКЫТ АЛА БАРЫН**
Дөнья куып син йөгергән чакта,
Мин кырыйда калдым сузылып
Һәм төшендем, бер ярдәмсез шулай
Төннәр сүнә икән суынып.

Гаепләмим, вакыт ала барын,
Тәэсир сүнә яшәү тәмемә.
Ут чәчсәң дә, көчең җитмәс сыман
Сүнеп килгән минем тәнемә.

Көчең җитмәгәнне аңлап микән,
Йомшаргандай сыман теләгең.
Авыр чакта көч артырга тиеш,
Шуны өмет итә йөрәгем.

Бик яшисем килә, көчем туплыйм,
Җылы тапмыйм бик нык теләп тә.
Ничек төшендерим, гомеремнең
Бар дәвасы синең теләктә.

*** * ***
Декабристлар бер дә теләмәгән
Илдә мескеннәрнең булуын.
Коммунистлар корытмакчы булган
Бар тармакта байлар токымын.

**ҮКЕНЕЧЛӘР КАЛМАСЫН**
Җырламаган җырларым күп,
Үкенечкә калырмы?
Җыр-моңнарым юлын табып
Дәверләргә барырмы?

Сандугачлардай сайрашып
Кунсаң иде гөлләргә.
Бәхетсезлекләр килмәсен
Безнең алгы көннәргә.

Яшәү ямьле көрәш белән,
Гөл үссә эзләремдә,
Түккән тир җимеш үстерсә
Гомерең көзләренә.

Тип, йөрәгем, ара күрмә,
Үкенечләр калмасын!
Тыңласын халкым җырымны,
Үзем белән бармасын!
*** * ***
Дусларны чәйгә чакырдым,
Ташлап булган эшемне.
Кайберләре килгән икән
Тикшерергә яшемне.

Рәхмәтне көтте күңелем,
Ул хурлады, карт диеп.
Апасына киңәш бирде,
Яшьрәкне тап диеп.

Дөрес сөйлим дип мактана
Кайбер мәгънәсезләр.
Ашка таракан ташлау бит
Җайсыз әйтелгән сүзләр.

Картларның фикер нык ул,
Бик бай матур акылга:
Киңәш итте чакырмаска
Җүләрләрне табынга.
**ХӘЙРИЯ ЕЛЫ**
Безнең кәсеп үзе изгелек бит,
Изгелекләр бизи көннәрне.
Бу ел әллә безнең йөрәкләрдә
Чәчәк аттырдымы гөлләрне?

Сау-сәламәт кеше күңелендә
Изгелекләр эшләү теләге.
Кешеләргә ярдәм иткәннәрнең
Күңеле шат, тыныч йөрәге.

Аш бир, су бир, изге гамәлләр кыл,
Җан җылыңны өләш халыкка.
Хәйрия елы күп изгелек белән
Кереп калсын безнең тарихка.

**МАМАДЫШЫМ**
Мамадышым – йөзек кашым минем,
Тирән эзең ерак тарихта.
Сокландыргыч табигатьне мактап
Дан җырлана сиңа халыкта.

Нократ дулкыннары назлап уйный
Ярларына яткан каласын.
Табигате назлый, назлагандай
Газиз ана иркә баласын.

Җиләк-җимешкә бай урман, кырлар,
Батыр халкы тырыш хезмәттә.
Нәтиҗәсен күреп өстәлләрдә
Яши мулдан, олы хөрмәттә.

Җырлап яши, яшәр гүзәл кала
Күп талантлар биреп дөньяга.
Гел изгелек телим, әллә шуңа
Бай яшисең хәер-догага.

**ЯЛГЫШТЫМ**

Мин иркәмне бүген яннарыма,
Ахры, көчләп кенә китердем.
Күңелендә ясалмалык сизеп,
Ялгыштым дип уйлап кителдем.

Җаны теләгәндә, башкачарак
Селкетә ул барлык кылларны.
Йөрәгеңдә мин юк идем бүген,
Суык сыман иде куллары.

Нишлисең бит, утын юешләнгән,
Тиз кабынып янып китми шул.
Шулпа сыек булса, шома телдән
Ач тамаклар туеп китми шул.

Гаепләмим, мин бит артык кашык,
Йомыш төшкән чакта кирәккә,
Урынын белеп, дулап китеп булмый,
Авыр булганда да йөрәккә.

Сабырлык бир, Ходам, бәлки, алда
Урын булыр йөрәк түрендә.
Җанны эретердәй матур хисләр
Чәчәк атар күңел күгендә.

**ТАБИГАТЬ ХАТАСЫМЫ**

Син шат булсаң, мин дә шат яшимен,
Син борчылсаң, мин дә борчылам.
Тәннәремдә шундый көчем булса,
Һич төшермәс идем учымнан.

Тәннәреңне сөттә юар идем,
Бирер идем сиңа муллыкны.
Гүзәллегең илгә игълан итеп,
Бүләк итәр идем зурлыкны.

Бар теләк тә әгәр кабул булса,
Җәннәт кошы синең урының.
Табигатьнең олы хатасыдыр
Хезмәт өчен генә тууың.

Кешелектә олы синең хакың,

Алла биргән сиңа мең сәләт.
Моңланма син, бәлки, могҗизалар
Бәхет өчен бирер бер сәбәп.
*** * ***
Нигә рәхәт икән яннарыңда,
Ник тартыла сиңа күңелем,
Шундый матур хис-хыяллар белән
Үтсә иде алда гомерем.

Мин канәгать, бер Аллама шөкер,
Карыйм бар дөньяга яратып.
Нәфес микән, гел тотасым килә
Сөйгәнемне күзгә каратып.
Юк, җәберләп һәм көчләп тә түгел,
Изгелекләр кылып үзем дә.
Нинди бәхет, җылы урын тапсам
Аның назлы күңел түрендә.

Ул да теләп, эзләп килсә иде
Иркә-назлар көтеп яныма.
Парлап бергә барып җитәр идек
Кешелекнең гомер язына.
*** * ***
Үзе юкта яман уйлар туа,
Оныттыра, килсә яныма.
Сүнәр сыман ярсуланган йөрәк
Ут төрткәндәй тагын кабына.

Ялгыз чакта чумып уйларыма,
Шикләремне санайм җүләргә,
Күңел тарткач, мәхәббәтне тапкач,
Борчылсам да кирәк түзәргә.

Борчылусыз шундый гүзәл белән
Бергә сулый алсаң һаваны,
Яшәр идең, бәлки, йөзгә кадәр,
Саулык өчен алып дәваны.

**ҮТӘ ГОМЕР НИЧЕК БУЛСА ДА**

Бүген көнем эчтәлексез үтте,
Үтә гомер ничек булса да.
Теләк юкта, мәгънәсе юк шул,
Алтын, көмеш явып торса да.

Бәхет бит ул байлык кына түгел,
Борчылулы булса күңелең.
Җаның теләгәннәр янда булса,
Бик бәхетле үтә гомерең.

Үткән көнне мин бәхетле идем,
Очып йөрдем каты арсам да.
Бүген менә кулым эшкә бармый,
Ямь табалмыйм кая барсам да.

Нинди бәхет, җаның теләгәннәр
Җилләр сыман сыйпап үтсә дә.

Оҗмах ләззәтләре сизәсең бит,
Уйнап-көлеп кенә үпсә дә.

**РӘНҖЕТМӘ**

Рәнҗетмәче, утын сүндермәче
Үзең теләп яккан учакның.
Югалтма син сихри гүзәллеген
Яшәү көче бирер кочакның.

Таңны көтәм. Кояш назлар сыман,
Сыкранганда туңган йөрәкне.
Җылы сулышларың бер үтәр бит
Өзгәләнеп көткән теләкне.

**КИЛ СИН ЯННАРЫМА**

Кил, бәгърем, кил син яннарыма,
Җаен табып, бәлки, үбәрсең.
Актык сулышта да янымда бул,
Тәнне юган суны түгәрсең.

Белеп булмый, Алла ни язгандыр...
Минем өчен син зур бүләктер.
Гомеремә еллар өстәр өчен
Синең мәхәббәтең кирәктер.

Аллам шулай сөйгән колларының
Гөл сибәдер йөрер юлына.
Сиңа булган изге теләкләрем
Мәңгеләшер туган җырымда.

**РӘХМӘТ СИҢА**

Өнем микән, әллә төшем булды,
Ләззәт күлләрендә су кердем.
Сагынганга микән, күзләремә
Оҗмах кошы булып күрендең.

Рәхмәт сиңа, мине аңлаганга,
Вакыт табып барын җайлаганга.
Йөрәгемнең әрнегәнен белеп,
Дәва табып майлаганга.

**НИГӘ КИЛДЕҢ?**

Күңелемне сагыш уты телә,
Эчтән сызам якты күрмичә.
Бу хыялый күңел һич басылмас
Һәм сүрелмәс, ахры, үлмичә.

Юк, орышмыйм, гаеп күрмим һич тә,
Тормыш юлы үзе бормалы.
Күрдем җирдә гүзәллекләр барын,
Теләгәнчә генә булмады.

**КАНАТЛАРЫМ ТИГЕЗ**

Мин бәхетле, канатларым тигез,
Күңел белән алга очарга.
Яннарымда бәхет, ләззәт бирер
Сөйгән карчыгым бар кочарга.

Гаеп санап яшьләр көлмәсеннәр,
Нинди ләззәт, имеш, картларда.

Олыларда булган тәмнәр булмый
Шашып йөргән яшьрәк чакларда.

Шаярулар белән яшьлек үткән,
Сөйгәнеңә хөрмәт бирмичә.
Олыгайгач, чын бәяли белгәч,
Яшәү авыр парың күрмичә.

Бик саклыйсы килә канатыңны,
Куркам бәрелүдән ярларга.
Озак яшисе килә бергә парлап,
Мәхәббәтне саклап җаннарда.

**ҖҮЛӘР, ДИМӘ**

Җүләр, димә, макта күңелемне,
Сөеп тартылган ич үзеңә.
Бәхет, ләззәт алып калам бит мин,
Син күренеп китсәң күземә.

Ышан, димәк, яшәү ялкыны да,
Юк, сүнмәгән әле тәнемдә.
Гомер үтә, беркөн акрын гына
Тынар йөрәк, сүнәр тәнем дә.

Шуны аңлап булган һәр мизгелнең
Әрәм итми алыйк кирәген.
Су сипкәндә үсәр гөлләреңә,
Чәчәкләнеп калсын йөрәгең.

**НИГӘ?**

Нигә шулай күрдең дә киттең,
Ут төрткәндәй, ялкын күңелдә.
Төтеннәрен күккә күтәрмичә
Янып яшәрменме гомергә?

Синең йөрәгеңә ут ягарга
Мөмкинлек юк, дөнья бозланган.
Миндә генә, күңел атынгандай,
Калынайган бозлар кузгалган.

Нигә шулай дөнья җайлы-җайсыз,
Теләгәнчә түгел язмышлар.
Бәхетсезлек берүк китермәсен
Көтелмәгән юк-бар ялгышлар.

**ЮК, ТУЙМАДЫМ**

Мин туймадым бүген, юк, туймадым,
Тәмле булды пешкән ашларың,
Андый тәмле ризыкларны, җаным,
Мин яшьлектә генә ашадым.

**ГАДЕЛСЕЗЛЕК ТУРЫНДА**

Йомышлары төшсә, белгәннәрем
Габделвахит диеп атады.
Йомыш юкта, кирәксезгә санап,
Артык кашык итеп санады.

Юкса әле генә тел шомартып,
Хөрмәт белән йөргән апалар
Эзләп тапкан йөрәк җылыларын
Янмый торган утка аталар.

Табигый хәл, еллар үзгәртәләр
Кешеләрнең тәнен, йөзләрен.
Дөнья малларыннан күзе тонып,
Оныталар әйткән сүзләрен.

Гаделсезлек, кабахәтлек булды
Кешеләрдә гомер-гомергә.
Бик кечкенә ихлассызлык та бит
Авыр тәэсир ясый күңелгә.

## СИХЕРЛӘНДЕМ, АХРЫ

Мин бүген шат, күңел очып йөри,
Беркем белми шуның сәбәбен.
Үзем генә беләм, тик бер кеше
Бирә миңа яшәү сәләтен.

Иркәлим дә мактыйм кайчак үзен,
Кайчак сүгәм үзе югында.
Сабыйларча эрим назларында,
Никтер рәхәт торса янымда.

Сихер диеп сөйләнмидер инде
Чын күңелдән сөя белгәннәр.
Мәхәббәттә янып көйгәннәрен
Һич төшенми сихер дигәннәр.

Сихерләндем, ахры, менә мин дә,
Күрми торсам, чиргә сабышам.
Төшләремдә күрешүләр көтеп,
Барыр юлларымны саташам.

Үзе тәмле, үзе гел борчулы,
Сабырлык бир, бирмә түзмәсен.
Барлык шатлык, газаплары белән
Сөеп яшәү мәңге сүнмәсен.

## БӘХЕТ БЕЛӘН ҮТСЕН КӨНЕБЕЗ

Бер җәй, бер кыш, бер яз, бер көз
Төрле хәлгә куя күңелне.
Үзгәрмәстәй бу мизгелләр бергә
Алып китә безнең гомерне.

Юк, үзгәрмәс, дөнья шулай барыр,
Матурлаучы без бит үзебез.
Канәгатьлек сизеп, бәхет тоеп,
Бәхет белән үтсен көнебез.

**КӨННӘР ӨСТИМ**

Илһамнардан эзләп энҗе тезәм,
Фикер, уйларымда изгелек.
Күңелемдә җырым, йөрәк җылым –
Дусларыма бирәм иң элек.

Сандугачлар моңы колагымда,
Иренемдә – җиләк тәмнәре.
Иркен сулап яшеллектә чабам,
Җиләс җилләр назлый тәннәрне.

Канәгатьмен һәрбер күренешкә,
Бәхет тоеп яшим күңелдә.
Табигатем көннәр өстәп яши
Кунак булып килгән гомергә.

*** * ***

Сыер савам, тирес ерам,
Бирмиләр хезмәт хакын.
Кешегә санамадылар
Гомергә авыл халкын.

Җитәкче күп, хуҗасы юк,
Бетте шулай авыллар.
Талыйлар, җимереп барын,
Үткәндәй җил, давыллар.

Каешланган авыл халкы
Үлми әле шулай да.
Комбайн сатып туена
Бер селәгәй малай да.

Көтү белән терлек китә,
Кая китә – белмиләр.
Өлеш эләккәнгә микән
«Кәттәкәннәр» күрмиләр.

Чиләк белән чүп җыялар
Кала урамнарында.
Иртә-кич машина юа
Урам тузаннарын да.

Итек киеп тирес ерам
Ипи, тозга, дәвага.
Чүп җыйсам да, хак түләрләр,
Китми булмас калага.

**ГОРУРЛАНУ**

Мамадышта һәрчак яз тәэсире,
Сары көзне сизми йөрәкләр.
Яшәр тормыш муллыгына,
Гомер, бәхет зурлыгына
Ирешүеңне көтә теләкләр.

Салкын кышта тәннәр туңмасынга
Яшәү ялкыннары кабынган.
Авырлыкка иелмәскә,
Явызларга бирелмәскә,
Күңел изгелеккә табынган.
Эшчән халкым таңнан ут уйната
Зур уңышлар өчен кырларда.
Табигатьнең матурлыгы,
Егет-кызлар батырлыгы
Илһам бирә туар җырларга.
Нократ-Чулман – безнең олы байлык,
Бик күп көмеш чишмә сулары.
Яңа үскән биек йортлар,
Һәр кабынган якты утлар –
Зур куаныч өсти шулары.

*** * ***

Мин бәхетле – янып сөя беләм,
Күп кешедә юк бит ул талант.
Сөям диеп, тәнгә тәм табалар,
Этләр сыман көчләп һәм талап.
Янып-сөеп, боздай эрү кирәк
Сөйгәнеңнең җылы куенында.
Шул чагында яшәр көч табасың,
Рухи байлык туа уеңда.

*** * ***

Нигә «кәттәкәнгә» бардым йомыш белән,
Шакып ишек ачтым керергә.
Мин көткәннән «кәттә» булып чыкты,
«Пошул» диде, мине күрүгә.

Борылдым да киттем, күңел сынды,
Ник бозыла шулай кешеләр?
Нигә юкка бүлмә били икән
Акылга сай сабый ишеләр.

Юкса урын һич гомергә түгел,
Онытканнар оча тизрәк.
Кешелеген бик тиз югалталар,
Юктан көрәк булса бигрәк.

Минем улларымнан кече малай
Көлгән сыман булды яшемнән.
Үз үлчәвен белмәгәне өчен,
Тиз куарлар аны эшеннән.

Килер бер көн, бәлки, очрашырбыз
Таяк тоткан хәлдә урамда.
Җитәкләрмен туры юлга сине,
Барыр юлны белми торганда.

**ЯЛГЫШ ЯЗМЫШ**

Явызлыкны кыла явыз җаннар,

Җәмгыятьтә алар хөрмәтсез.
Хакимлектә явыз урын алса,
Һич көтмәгез, файда күрмәссез.

Сәясәттә явыз хөкем итсә,
Юк, ышанма, барма артыннан.
Атка менеп кулга кылыч алса,
Бәреп төшер аны атыннан.

Юл куябыз кайчак, сәбәбе шул:
Без ул – йомшак мәмәй авызлар.
Бик пошынып язам бу юлларны,
Хакимлектә бүген явызлар.

Табигатьтә түгел, кешелектә
Күп очрый шундый ялгышлар.
И бер Аллам, сәҗдә кылып сорыйм,
Насыйп кылма андый язмышлар.
*** * ***
Сиксән ул туксан түгел, кыерсытма,
Карт дип санап минем елымны.
Йөрәгеңә салып, ныклап тыңла
Саклап килгән яшьлек җырымны.

Кырык яшьлек картның елын сана,
Үзең уйла кая язарга.
Кәгазьдәген түгел, чынбарлыкны
Кирәк дөрес итеп санарга.

Ничә еллар, гайрәт чиксен диеп,
Игътибарсыз күрми узасыз.
План диеп, кәгазь өчен генә
Уйламыйча өстәп урасыз.

Олы түрә хаким өчен түгел,
Хезмәтемне бирәм халыкка.
Нинди көч тә каплый алмас хәлдә
Тирән эзем калыр тарихта.

## АҢЛЫЙК БАРЫН

Җир әйләнә. Ничек тырышсак та,
Туктатырга булмас мөмкинлек.
Сикергәләп җирдән күтәрелмик,
Бергә телик илгә иминлек.

Бүгенгесе белән канатланып,
Авырттырмыйк башны бәрелеп.
Мәгънәсез түбән тәгәрәмик,
Көчең җитмәгәнгә үрелеп.

Аңлыйк барын. Алла акыл биргән,
Акыл белән үтик гомерне.
Мәгънәсез, юньсез уйлар кереп
Бутамаса иде күңелне.

* * *

*Кадерле туганым Миңгол Галиевкә*

Горурланып әйтәм:
Изге эзең тирән дөньяда!
Туган-тумачалар, якташларың –
Бар да сиңа хәер-догада.

Син ат көткән тугай, үзәннәргә
Кайт, эзләргә яшьлек эзеңне.
Тыңларсың, шәт, тургай, былбылларны,
Яшьлектә хис итеп үзеңне.

Син су кергән инеш буалары
Суы саекса да саклана.
Сине күрсәк, моңлы җырларыңнан
Йөрәк эри, күңел шатлана.

Яратабыз, хөрмәтлибез сине,
Исемеңне йөртеп күкләрдә.
Җырда моңың, гади кешелегең
Күчсен иде әле күпләргә.

Тыңлыйлар бит безнең татар җырын
Күп милләте чит, ят илләрнең.
Сүнмәс йолдыз булып янасың син
Якташларның, туган җирләрнең.

Күңелемдә минем изге теләк,
Иркәр идем сыйпап башыңнан.
Тәбрик итеп сиңа сәлам юллыйм
Якташлардан, нигез ташыңнан.

## КЕМ ГАЕПЛӘР?

Үз гомеремдә олы хөрмәт белән
Булганым бар Тукай-Кырлайда.
Хөрмәтем шул: горурлыгым никтер
Арткан сыман туган Тулбайда.

Күрәм, беләм, Идел зур һәм көчле,
Мин яратам Нократ буйларын.
Шул суларда тәнем югангамы,
Шунда туа изге уйларым.

Рәнҗемәсме Идел дулкыннары
Яратканга Нократ давылын?
Мактап җырлыйм олы калаларны,
Төшкә керә туган авылым.

Биотоклар минем шундый инде –
Читтә инеш тарта күңелне.
Туган якның урман, болыннарын
Мактап җырлап үттем гомерне.

Үз ягымның һәр кешесе якын,

Хөрмәт итәм Тукай-Кырлайны.
Кем гаепләр, әгәр артык күрсәм,
Шәйхи Маннур үскән Тулбайны.

**ӨМЕТЕ БАРНЫҢ ГОМЕРЕ БАР**

Өмет белән яшә киләчәккә,
Күңел күзең күрсен яктылык.
Хөрмәт белән яшәү кирәк булса,
Кешеләргә эшлә яхшылык.

Гел рухланып яшәү мөмкин булса,
Изгелекләр арта теләктә.
Хөрмәт булса, яшәү матурлана,
Шатлык тула күңел, йөрәккә.

**КӨЧЛӘР ТАБЫЛЫР**

Гаделлекләр эзләп үтә гомер,
Кайчак күрәм, бик тиз югала.
Нахал, явыз күп чак этә-төртә
Түргә чаба, өскә юл ала.

Гаделлекнең тамырлары тирән,
Гел яңара, ләкин таптыйлар.
Шытып чыккан саен орлыклар да,
Су тимәгәч, чәчәк атмыйлар.

Өмет яши: табигатьне төптән
Үзгәртердәй утлар кабыныр.
Гаделлекләр чәчәк атсын өчен,
Су сибәрдәй көчләр табылыр.

*** ***

Үткәннәрем әкият түгел минем,
Тирән эзләр калды юлларда.
Канлы сугыш, ачлык. Авыр хезмәт
Туры килде яшьлек елларга.

Яланаяк сабан сөргәннәр,
Салкын кышта юлда түзгәннәр,
Сабый, малай чакта күргәннәр
Истән чыкмый, бомба шартлаганда,
Чокыр эзләп качып йөргәннәр.

Иртә килгән тәүге үкенечләр –
Төзәлмәстәй алган сагыш та.
Мыек чыкканчы ук, озын шинель киеп,
Солдат булып киттек сугышка.

Сослонгирның нарат урманнары,
Окоп казыр комлы урыннары
Ачлык өстәп тәнне иләде.
Һава десантчысы, бокс спортчысы–
Истәлекле яшьлек бизәге.

Мин сугышның үрләрендә булдым,
Сагынып сөйләр эзләр күп калды.
Юлларымны еллар күп үзгәртте,
Күккә менәр ният югалды.

**АКЫЛСЫЗЛАР**

Чәчәкләргә төреп, хөрмәт белән
Түргә куяр затны хурлый бит.
Үзе яшәр дөнья базарында
Юкса бер тиенлек тормый бит.

Шаулап-гөрләп яшәр урынында
Аракыга тыга тиенен.
Хезмәт сөйми, аны туйдырсыннар,
Хатын тапсын аңа киемен.

Эшлим диеп, кайчак күкрәк суга
Күршесенә кадак какканын.
Кайсы риза булсын, күреп, белеп,
Бар тапканын үзе какканын.

Гаилә бит үзе кече дәүләт,
Яши, бар ягын да көйләсәң.
Акыл тупла, гадел фикердә бул,
Тормышыңа бәхет теләсәң.

**ОНЫТМА**

Оныттыңмы әллә мин барлыкны,
Чаба-чаба дөнья куасың.
Уйлыйсыңмы кыска гына кунак
Гомерләрнең әрәм узасын.

Җылы сүз дә җанга ләззәт бирә,
Бер күрешү үзе бер гомер.
Яратканнар янда күренсә дә,
Канатланып кала ул күңел.

**ИЗГЕ ЭЗЛӘР**

Биек таулар, тирән елгалар бар –
Табигатьнең эзе тарихта.
Җир йөзендә көчлеләрнең эзе
Ядкарь булып яши халыкта.

Мәңгелеккә исем калсын өчен,
Теләкләр күп, җитми сәбәпләр.
Тирән эзләр салыр өчен кирәк
Аллаһыдан иңгән сәләтләр.

Зур даһилар итеп баш иябез
Такташ, Муса, Пушкин, Тукайга.
Шәйхи Маннур ул безнеке диеп,
Суытмыйбыз эзне Тулбайга.

Мәчет, мәдрәсә, юл, музей төзү,
Китап язу – лаек догага.
Кешелеккә булган изгелекләр –
Алар бар да эзләр дөньяда.

Изге эзләр калсын хәдис сыман,
Кабатласын килер буыннар.
Кешелектә яманлыкка һич тә
Бирелмәсен иде урыннар.

**СОРАП ТҮГЕЛ**

Картаям бит, ләкин сорап түгел,
Табигать бит шулай җайланган.
Кирәк урыннарда буыннар да
Тиешенчә генә майланган.

Мае беткәч, техникада да бит
Ватылгалый майсыз урыннар.
Мае беткән ат арбасы сыман
Шыгыр-шыгыр килә буыннар.

Юк, борчылып зарлануым түгел,
Үзләренә әйтәм яшьләрнең.
Минем өчен инде гаеп түгел,
Шөкер, картайганчы яшәдем.

Картайдым дип әле кул селтәмим,
Изгелекләр бик күп уемда.
Эзләремне тирән калдыралсам,
Хөрмәт булыр соңгы туемда.

**СИН ГЕНӘ УЙЛАРЫМДА**

Яз-көз – томан, кышын – буран
Нократ буйларында.
Томаннарда, бураннарда
Син генә уйларымда.

Бүген сине төштә күрдем,
Урамнан үткәнеңне.
Өзгәләнеп искә алдым
Яратып үпкәнеңне.

Җил кермәсен, ача күрмә
Тәрәзәң өленгесен.
Шөкер итеп кадерен бел
Бәхетнең бүгенгесен.

**СИНЕ ЭЗЛИ**

Юләр күңел сине эзли,
Юлларыңда – күзләрем.
Тамырланып тирән кергән
Йөрәгемдә эзләрең.

Гомер язын син китердең,
Көзен дә ку еракка.
Чәчәкле күңел хисләрен
Саклар идең озакка.

**БӘЛКИ**

Мин сагынам үткән ямьле кичне,
Җанга гүзәл гөлләр тулдылар.
Сүнеп барган йөрәк, күңелләрдә
Ялкынланган хисләр тудылар.

Гел кочасым, гел саклыйсым килә,
Җибәрмичә яннан үзеңне.
Көннәр буе бүген очып йөрим,
Бик бәхетле санап үземне.

Яшә, бәгърем, Алла саулык бирсен,
Көткәнемне, бәлки, бирерсең.
Бер йотымлык назга кибеккәндә,
Мине яшәтергә килерсең.

**СӨБХАНАЛЛА!**

Ап-ак кар өстеннән, салмак атлап,
Нур сипкәндәй бара урамда.
Алла биргән гүзәллекне күреп
Хәйран калам уйлап торам да.

Төсе, бите, гәүдә сылулыгы!
Киемнәре үлчәп тегелгән.
Күз тимәсен берүк, бигрәк гүзәл,
Соклandырып күз күремгә,
Бик килешле итеп киенгән.

Төчеләнеп көтәм, әллә чирлим,
Саранлыкмы туя белмәвем?
Шәүләң дә бит мине назлап үтә,
Сине күреп йөрсәм үлмәмен.

*** * ***

Күңелем шат, рәхмәт сиңа,
Бәйрәм бирдең бүген көнемә.
Дөнья михнәтләрен оныттырдың,
Шатлык килсен иде үзеңә.

Тыныч тормыш, саулык телим,
Янымда син булу яшәртә.
Учларымда йөргән кайнар сөю
Гомер өсти миңа, яшәтә.

*** * ***

Язлар күмә җирне гүзәллеккә,

Чәчәкләре бирә җимешләр.
Яз яңарта сүнгән хыялларны,
Тулып-ташып ага инешләр.

Язлар биргән гүзәл чәчәк кебек,
Сез тугансыз елның язында.
Шуңа, бәлки, тәкъдир куйган сезне
Кешеләргә бәхет язарга.

Матур хисләр, изге теләгемне
Яз нурлары белән урадым.
Озын гомер, бәхет, шатлык телим,
Кабул булсын иде, Ходаем.

**ДӘҮ ӘНИЕМ!**

Кадерлебез безнең, дәү әнием!
Олы хөрмәт сиңа йөрәктә.
Оныкларың, якыннарың бар да
Яши изге, матур теләктә.

«Балам» дигән иркә, йомшак сүзең
Көч биргәндәй безгә үсәргә.
Сабырлыгың, юмарт йомшаклыгың
Өйрәтәдер тормыш кичәргә.

Алла сиңа саулык, гомер бирсен,
Борчылулар ишек какмасын.
Картлыкның да әле явызлары
Бик тиз генә сине тапмасын.

Дәү әнием! Бу – бәйрәм яшең,
Ул олысы үткән гомернең.
Бик яратып сине тәбрик итәм,
Бу – яшьлеге алгы көнеңнең.

Күп мәртәбә кабатлансын иде
Бүгенгедәй бәйрәм көннәрең.
Шиңмәсеннәр, гел чәчәктә торсын
Җимеш бирер күңел гөлләрең.

**ШАҺИНУР МОСТАФИНГА**

Кешелегең, матур мөгамәләң
Тарта дусларыңны яныңа.
Күңел җылылыгың картларны да
Алып кайта гомер язына.

Эзләнүләр, олы хезмәтләрең
Хөрмәт яулый сиңа халыкта.
Давыллардан үткән Синең шәхес
Тирән эзле инде тарихта.

**СҮРЕЛМӘСЕН**

Күңелемдә чәчәкле яз минем,
Кыш салкынын сизми тәннәрем.
Яз хисләре белән коендырып,
Сиптең миңа яшәү ямьнәрен.

Гомер көзем саргайтмакчы була
Чәчләремә сылап тапларын.
Күңелемдә булган яз гөлләрен
Синең җылың белән саклармын!

**КАРТАЙМАДЫМ ӘЛЕ**

Хисләремдә әле картлык сизмим,
Яшьлек очкыннары күземдә.
Күңелемдә озын юллар ята,
Йолдызларым балкый күгемдә.

Рухым белән әле тау күчерәм,
Юк, ташламыйм йөкне кулымнан.
Бәхетемне хәрәкәттән эзлим,
Ләззәт тапмыйм йомшак урыннан.

Картайдың, дип авыз чайкамагыз,
Яшәү көчем – диңгез кичәрдәй.
Дәрт-дәрманым кайный тамырымда
Мескен егетләргә күчәрдәй.

Еллар белән, дөрес, гомер үтә,
Яшәү сүнә, әгәр сүрелсәң.
Кырыкта да картаерга мөмкин,
Каршы искән җилгә бөгелсәң.

**СИН БУЛГАНДА ГЫНА**

Иренемдә иреннәрең тәме,
Сулышымда якты исләрең.
Йөрәгемдә ялкынланып тора
Чәчәкләнгән сөю хисләрем.

Синең янда гына көн кояшлы,
Чәчәк ата гүзәл гөлләрем.
Син булганда гына яннарымда
Бәхет тоеп үтә көннәрем.

**ПЕШМӘГӘННӘР ТУРЫНДА**

Язмыш булгач, ялгышы да була,
Түрә була кайбер пешмәгән.
Күккә карап ботагында чери
Пешмәгәнгә җиргә төшмәгән.

Бар имгәкләр, хуҗа булдым диеп,
Дөрес бәяләми урынын.
Беркемдә дә аңа хөрмәт калмый,
Күтәргәләп йөрсә борынын.

Хөрмәтләми олы булмак була,
Кешелексез кеше ишеләр.
Яратсыннар, файда, хөрмәт күрсәт,
Безнеке дип йөрсен кешеләр!

**ЫШАН СИН**

Сагынып кешең булу – үзе бәхет,
Борчый җанны күрми торганда.
Кадерләрен белеп назлый микән
Җае килеп бергә булганда.

Әй бер Аллам, саулыгымны сакла,
Мөмкинлек бир иркә назыңа.
Җан сөйгәнем белән бергә илт син
Күңелемне яшьлек языма.

Икеләнмә минем сүзләремә,
Сөям сине, сөям мин, җаным.
Белеп яшә, ышан чынбарлыкка,
Мәхәббәтнең яше юк аның!

**УЙЛАНУЛАР**

Тәм белмисең, ямь күрмисең,
Аракыга өйрәнсәң.
Талашмыйсың, сугышмыйсың,
Телсезләргә өйләнсәң.
Көнләшкән булып кылансаң
Гомер итәр хатынга,
Анда ныклы терәк туар
Башка ирләр катында.
Кайбер ирләр акча эшли,
Әрәм итә тапканын,
Атна үтми, сизми кала
Буш кул белән ятканын.
Эш урынын файдалансаң
Урлап кына баерга,
Урлаган мал йокы бирми –
Менә шунда аерма.
Мал тапканда өстәл төйсәң
Хатынга, балаларга,
Бу үзеңә урын көйләү
Картайгач җәзаларга.
Гаиләдә тавыш чыкса,
Йөр бәхетсезлек көтеп.
Сәбәп эзләп ерак китмә,
Эзлә үзеңнән элек.
Тәмле тел – йөрәк азыгы,
Бәхет нигезе – хезмәт.
Мөгамәләң матур булса,
Үзеңә булыр хөрмәт.
Гомер итү бик катлаулы,
Уйлап яшәргә кирәк.
Омтылсаң айга менәргә,

Озак яшисең, димәк.

Ел әйләнә искә төшер
Чәчәкле яз гөлләрен.
Гүзәл чәчәкле булырлар
Алда гомер көзләрең.

**ЯШИМ ДОГАДА**

Синең янда җилләр үзгәрмиме,
Туңдырадыр төнге җилләре.
Йөрәгеңне ашап борчыйлар шул
Якыннарның заман чирләре.

Күңел борчылырдай сәбәбең бар,
Читтән генә яшим күзәтеп.
Теләгем бар, ләкин мөмкинлек юк,
Булмый һич тә җайлап, төзәтеп.

Язмышлар да бер үзгәрер әле,
Могҗизалар бар ул дөньяда.
Алгы көннәреңә бәхет теләп,
Бер Аллага яшим догада.

**ӘММА ШУЛАЙ**

Гомеремне мәңге онытылмастай
Эшләр белән килә бизисем,
Яшәгәндә, барлык кешеләрне
Бик бәхетле итеп күрәсем.

Гомеремне ничек булса да мин
Изге эшләр белән чикләрмен.
Нәфесемне хәрам, явызлыктан
Олы йозак белән бикләрмен.

Мөмкин булса, йөрәк җылымны да
Кешеләргә бүлеп бирермен.
Рус, керәшен, бай, ярлысын да
Туганымдай якын күрермен.

Алла насыйп иткән ризыгымны
Якыннарым белән бүләрмен.
Алар өчен, бер Алламнан сорап,
Кирәк булса үзем үләрмен.

Белмим, булыр микән, әмма шулай
Күңел изгелеккә үрелә.
Шуңа микән әллә төшләремдә
Оҗмах ачкычлары күренә.

**ШУЛ ЧАГЫНДА**

Йөрәгемне сиңа бирер идем,

Мин йөрәксез яши алмамын.
Тирән сагышларын үттек инде,
Гел бәхеттә яшик калганын.

Тальян моңнарыннан яшем ага,
Үткән эзләр кыса сулышны.
Очар канатларым кыскарганга,
Каһәрлимен үткән сугышны.

Яшьлек мизгелләре искә төшә,
Тәм тапканым җиккән атымнан.
Үзем үреп кигән чабатадан
Чапкан идем синең артыңнан.

Яшен булдым, яшьнәп яши белдем,
Шул булгандыр сөю талантым.
Авыр чакта, хром кигәндә дә,
Чын йөрәктән сине яраттым.

Гомер телим, ләкин чиге бардыр –
Калмый хатын, калмый ире дә.
Соң мизгелдә синең назлы кулың
Су тидерсә иде ирengә.

## ӨЗЕЛМӘСЕН ТАМЫРЛАР

Кышын буран, җәен тузан
Безнең юлларда, туган.
Шул буран, тузан эчендә
Без бит дөньяга туган.

Кыргый маллар кырда туа,
Кырда гомере уза.
Нәкъ табигать җайлаганча,
Балыклар яши суда.

Бар дөньяның калалары,
Бар комлы далалары.
Ашарга ипи үстергән –
Без авыл балалары.

Кыргый мал кырда туена,
Тик суда үрчи балык.
Туып үскән җирдә генә
Бәхетле яши халык.

Үссен дигән үсемлекне
Өзмәгез сез тамырдан.
Авылда туган баланы
Аермагыз авылдан.

## БУЛГАН ЧАКТА СӘЛӘТЕҢ

Рухланып эшләгәндә

Канатлана сәләтең.
Канатлану көче бирә
Назда үткән сәгатең.

Ашта, эштә иркә, наз да –
Матур яшәүгә сәбәп.
Кайберәүдә берсе дә юк,
Ходай бирмәгәч сәләт.

Яшәвеңнең кадерен бел
Чәчәктә чакта гомер.
Бер сәләт тә кирәк булмас,
Картаеп шиңсә күңел.

**ӘЛЛӘ ШУНДА ТУЫП ҮСКӘНГӘ**

Туган якның һәр мизгеле изге,
Чәчәкле җәй, салкын кышы да.
Күңелләрне тарта күк-диңгезгә
Күктә очып үткән кошы да.

Җәймени ул, кояш кыздырмаса,
Яшел үлән, җимеш үсмәсә.
Нинди кыш ул, кар-бураннар уйнап,
Кар өярдәй җилләр исмәсә.

Табигатем мине назлый сыман,
Нинди генә җиле иссә дә.
Туган якның һәр мизгеле якын,
Әллә шунда туып үскәнгә.

**БӘХЕТЛЕ ГАЗАП ТУРЫНДА**

Үзе газап, үзе бәхет тә ул
Сагынып яшәр кешең булуы.
Һәркемнең дә күңел түрендәдер
Сөйгәннәрнең яшәр урыны.

Мәхәббәтне һич аңлатып булмый,
Күренми ул кеше күзенә.
Газабы да, шатлыгы да бергә
Сөя белгәннәрнең үзендә.

Теле сөйли, үзе һич ышанмый
Мәхәббәтнең утлы көченә.
Андыйлар бит өстән генә йөзә,
Чума белми ялкын эченә.

**ЙӨРӘКЛӘРНЕ САКЛЫЙК ЯРАДАН**

Ник очрадың гомер көзем килгәч,
Язларымда кайда йөрдең син?
Җәйләремдә үскән җиләкләрне
Сиңа җыйган булыр идем мин.

Минем гөлләр язын чәчәк атты,

Син бөредә генә булгансың.
Яфрак ярып чәчәк аткач кына,
Минем юлларыма узгансың.

Көзен гөлләр чәчәкләрен коя,
Белмәдеңме көзнең киләсен.
Ялгышкансың икән, юк, үкенмә,
Ни күрсәң дә хәзер – түзәсең.
Табигый хәл. Тормыш үзе куша:
Суга төшсәң, кирәк чыгарга.
Нәфес белән йөкне бер төягәч,
Туры килә инде чыдарга.

Һәркемгә дә гомер санаулы ул,
Сиңа да бит килмәс яңадан.
Озын язлы көзләр килсен өчен,
Йөрәкләрне саклыйк ярадан.

**КИЛСЕН ЯЗЛАР**

Түбәләрдән бүген тамчы тама,
Гөрләвекләр булып су ага.
Тау битләре инде яшәргәннәр,
Карны ертып калка Җир-ана.

Киткән кошлар кире кайтыр тиздән,
Яшеллекләр күмәр төбәкне.
Чәчәк аткан гөлләр гүзәллеге
Үзгәртерләр уйны, теләкне.

Бар табигать яз дип яңарганда,
Хис-хыяллар ничек тумасын!
Килсен якты язлар, килсен тагын,
Тик соңгы яз гына булмасын.

**ҺӘРКЕМГӘ НАЗЛАР КИРӘК**

Кайнар мәхәббәт чишмәсен
Төшенегез, аңлагыз.
Сөйгәнегезне һәрвакыт
Иркәләгез, назлагыз.

Иркә-назлар канат бирә
Адәм балаларына.
Авыр сүз тозлар салгандай
Йөрәк яраларына.

Гомерләр үтсен назларда,
Яшьнәп яшәргә кирәк.
Наз саулык бирә тәннәргә –
Гомер өстәлә, димәк.

**КҮҢЕЛ НЕЧКӘ**

Күңел нечкә, тиз авыша

Әкрен искән җилгә дә.
Гөлләр гүзәллек, ямь өсти,
Чәчсәң нинди җиргә дә.

Әздән күңел канатлана,
Кителә кыек сүздән.
Яратканыңны күргәндә,
Нишләп нур чыга күздән?

Алла, авыр, көткәннәрең
Эндәшмичә үтсәләр.
Дөньяда берни кирәкми,
Бер кочаклап үпсәләр.

**ЯРАТУ КИРӘК**

Өзелеп яраткан чагында
Хөр кеше дә гүя кол.
Яратмыйча үбешкәндә
Җирәндерми микән ул?

Ярату ул – йөрәк хисе,
Аңлау, уйлану кирәк.
Яраткан булып үбешү –
Кылану гына, димәк.

Тәннең тәмен бозык кеше
Бүлеп бирә өлешкә.
Сүзен тыңлыйм дигән булып,
Яратмыйча үбешә.

Җаннарыңа ләззәт тула,
Үбешсәң әгәр теләп.
Яратмаган кешеләрне
Ничек үбәргә кирәк!

**БӘХЕТЛЕ СИН ӨЗЕЛЕП СӨЙГӘНДӘ**

Йолдызлар да никтер моңсуланды,
Томан аша гына күренә.
Кинәт кенә йолдызларың сүнсә,
Күңел ялкыны да сүрелә.

Җүләр күңел кайчак чама белми,
Йолдыз тотмак була һавадан.
Яшьлек хисе ничек тилертсә дә,
Туып булмый инде яңадан.

Уңай килде дип сөенәбез,
Көенәбез кире килгәндә.
Кеше бәхетле бит гомерендә,
Картайгач та сөя белгәндә.
**ТӨГӘЛ КИРӘК**
Укалар бик тиз коела,
Укалыны кимәгез.

Укалыга кызыкканны
Яратмагыз, сөймәгез.

Яшәргә гүзәллек бирә
Кешелек һәм гаделлек.
Бәхет сизәсең сөйгәннән,
Белсә синең кадерне.

Бар күренеш төгәл кирәк,
Күп тә, ким дә килешми.
Мактанганнар, зарланганнар
Теләгенә ирешми.

**ЯРАТЫГЫЗ КАРТЛАРНЫ**

Кирәк тапсагыз назларда
Мәхәббәтне саклауны,
Сөяркә итеп тотыгыз
Безнең ише картларны.

Акыллы булган хуҗалар
Мактап җиккән атларны.
Хуҗабикә иркә-назда
Саклый белгән картларны.

Артык авыр китермәгән,
Җайлый белгән шартларны.
Аңлый белгән хатын һәрчак
Ярата ул картларны.

Яшь диеп, телгә кызыгып,
Китермәгез ятларны.
Мәхәббәт уены өчен
Саклагыз сез картларны.

**БИК КАДЕРЛЕ СИН МИҢА**

Аерым торганда беләсең
Бер-береңнең кадерен.
Ашым пешкән, үзем әзер,
Кайтчы тизрәк, бәгырем.

Сагындым, күзгә күренсәң,
Кысып, кочып үбәрмен.
Ал куеныңа, төреп назга,
Нишләтсәң дә түзәрмен.

Телем белән сөйлим барын,
Бер ялгансыз дөресен.
Йөрәк, күңел тапсызлыгын,
Исән булсак, күрерсең.

Саулык телим, бәхетле бул,
Шул сиңа миннән теләк.
Гомер гөлен шиңдермәскә

Син Алладан бер бүләк.

Гел саклыйсым килә сөеп,
Тап тидермичә сиңа.
Яшисем килгәнгә микән,
Бик кадерле син миңа.

*** * ***

*Хөрмәтле Рөстәм Галиулловичка*

Сез матурлык эзләүче, бирүче,
Тирән эз ясаучы тарихка.
Изге хәдис булып сакланырлар
Сез кылганнар безнең халыкта.

Акылга бай, рухи яктан нык сез,
Каршылыклар килсә җиңәргә.
Алла сәләтен дә мулдан биргән
Бик күп көчне эшкә җигәргә.

Диңгездәге көчле давыл сыман
Бик катлаулы еллар үтәсез.
Дилбегәне тоткан хәлдә, безне
Җимеш бирер ярга илтәсез.

Хезмәт җимешегез өмет бирә
Бүгенгегә, килер буынга.
Күпләр әле алда дан җырларлар
Сезнең хезмәтегез турында.

*** * ***

*Якташым Шәйхи Маннур истәлегенә*

Сезнең заманда да булгандыр ул
Гаделсезлек – йөрәк әрнеткән.
Дан җырлыйсым килә шәхесләргә –
Каләм белән ташны эреткән.

Корал белән, үткен каләм белән
Дошманнарны җиңгән кеше син.
Йөрәк әрнегәндә, җаннарыма
Синең әсәрләрне эзлим мин.

Кушылам мин күңел серләреңә,
Тотынгандай синең кулыңа.
Зур маяклар үсеп чыккан сыман
Алга атлап барыр юлыма.

Бик таләпчән, дөрес караш күрәм
Синең язган, үткән эзләрдән.
Көч алгандай булам йөрәгемә,
Сакланганда явыз күзләрдән.

Зур көрәшләр белән үтә гомер,
Син көч бирдең үткән юлымда.
Гаделсезлек белән көрәшергә

Каләмемне саклыйм кулымда.

Күңел күзем яктылыклар эзли,
Куллар үрелсә дә таякка.
Мин Тулбайга киләм өмет белән
Язар хисләремә маякка.

*** * ***

Йөрәк елый, күңел сызлый бүген,
Яшем генә чыкмый күземнән.
Качар идем, әгәр мөмкин булса,
Дөньясыннан, бигрәк үземнән.

Урын тапмыйм, ямен уйлаган юк,
Гел караңгы күңел күкләрем.
Мин нишләдем, һич аңламыйм, юкса
Көндәшчесе идем күпләрнең.

Алып кит син мине бер мизгелгә,
Сулышларың белән дәвала.
Табиб тапмый, даруханә сатмый –
Тик син кирәк миңа дәвага.

*** * ***

Үзем юлда, корал кулда,
Белмим, күпме барырмын.
Киек, җәнлек текә тауда,
Бәлки, арып калырмын.

Таулар биек, күрмим киек,
Йөримен яныпкөеп.
Борчылып йөрим буранда,
Сине күрәсем килеп.

Авыр хәлдә мин шул мәлдә
Буталган инде күңел.
Җил-буран, чатыр-чотырдан
Көчкә үрмәли гомер.

Шушы мәлдә син тотасың
Белеп, әллә белмичә.
Йөрим караңгы дөньяда,
Хәтта сине күрмичә.

**НИК КИЛМӘДЕҢ?**

Ник киттең син минем яннарымнан,
Гомерлеккә нигә калмадың?
Әле киләм, көт син мине, дидең,
Юк, килмәдең, никтер алдадың.

Мин бит көттем, көтәм әле һаман,
Юлларымнан алмый күземне.
Аллам насыйп итәр әле, бәлки,
Бер күрергә нурлы йөзеңне.

Иркәлисем килә битләреңне,
Куа алмыйм сине исемнән.
Олы таудай бәхет өстәр идем,
Килер булса минем көчемнән.

Бәхил бул син, әгәр күрешмәсәк
Гомер барда фани дөньяда.
Күчкәндә дә, изге хисләр саклап,
Калыйк изге хәер-догада.

*** * ***

Артистлар гына кылана
Чынны очратмыйча.
Үбешкән булып кылана
Авыз пычратмыйча.

Артистланып ялган кертсә
Мәхәббәт уенында,
Җанлылар ничек эресен
Андыйлар куенында.

Гадел, чын, саф мәхәббәтне
Тели акыл иясе.
Яшәү тәме кирәк булса,
Сөясе, сөеләсе.

Яшәсен сөю утында
Янганнар һәм көйгәннәр.
Мәхәббәтне саклау өчен
Үлсәм, үләм дигәннәр.

**ЯЗЛАР ТЕЛИМ**

Күңеленә, иркәм, язлар телим,
Якты күңел бай ул язларга.
Кем теләми икән гомеренең
Үткәнлеген иркә-назларда.

Килсен язлар, бирсен бик күп назлар,
Ямьләндереп безнең күңелне.
Теләгәнчә иркә назлар белән
Үткәрербез, бәлки, гомерне.

*** * ***

Теләп алган картаң
Авыр сиңа, беләм, авыр инде
Тигезләргә бик күп теләкне.
Теләп алган картаң, авыр диеп
Яралама, зинһар, йөрәкне.
Телең, тәмең белән юл салдың бит
Назга тансык тәнгә, күңелгә.
Тәннәреңнең тәмен,
Көннәремнең ямен

Бик саклыйсым килә гомергә.

## ЙӨРӘКТӘГЕ ТЕЛӘК

Утын төрттең, сүндермәдең,
Янам яткан урында.
Уйлап бетермисең кайчак
Минем теләк турында.

Юләр димә, юләр түгел,
Гаеп үзеңдә бугай.
Яуладың бөтен дөньямны,
Хәзер интегәм шулай.

Күзем йомсам, шәүләң күрәм,
Ирендә синең тәмең.
Яннарымда тота алмыйм –
Бик авыр минем хәлем.

## БЕЛЕП ЯШИК

Яннарымда сине тойсам,
Очып китмәкче булам.
Син югалсаң, алгы көнем
Куе томаннар сыман.

Таңнан көтәм, хәбәр юкта
Күңелем никтер боек.
Сине күрми торсам әгәр,
Йөрәгемә тынгы юк.

Таң җилләре кояр сыман
Чәчәген күңелемнең.
Син, бәгырем, белеп яшә,
Чәчәге гомеремнең.

Гөлләрнең бит матурлыгы
Чәчәк аткан чагында.
Минем күңел чәчәк ата,
Син булганда янымда.

## НИ ХИКМӘТТЕР

Быел кышын карлар бик күп яуды,
Яз кар суы менә тауларга.
Кар сулары күтәрелгән сыман
Күтәрелә бәя товарга.

Бәя артыр, баер илебез дә,
Тик кешеләр генә интегә.
Пенсия дип биргән акчалары
Җитәр микән ашар ипигә?

Ил бай диеп, бәлки, мактанырлар
Илне талап чергән түрәләр.

Байлыкны бит үз халкында түгел,
Чит ил кассасында күрәләр.

Халык та бит юкса сарык түгел,
Барын белеп тора, күрәләр.
Ил талаган түрәләргә генә,
Ни хикмәттер, һаман түзәләр.

## ҮЗГӘРӘ КИРЕГӘ

Йөрәк сызлап сыкрана халык,
Гаделсезлек борчый күңелне.
Хезмәт өчен тиен, ә түрәгә кием,
Бу соң гаделсезлек түгелме?

Дәвага да зур акчалар кирәк,
Олы акча була байларда.
Түләмичә уку, дәвалану
Булган көннәр китә кайларга.

Гөмбә сыман калка зур сарайлар
Халык өчен түгел, түрәгә.
Дәвалану урыннарында да
Дару өчен кирәк түләргә.

Тормыш шулай төптән үзгәртә шул,
Тик уңайга түгел, кирегә.
Кешеләрне дәүләт үзе талый,
Бик уйламый үзе бирергә.

## ҖАННЫ ӨШЕТӘ

Ир-егетне тиз сүндерә икән,
Бармакларга алтын кисәләр.
Картаюга сәбәп түгел микән
Артык гүзәл булса сөйгәннәр?

Күп чак үреләбез югарыга,
Чама килми диеп тормыйбыз.
Кешеләрдә шәхес зурлыйбыз дип,
Үзебезне үзебез хурлыйбыз.

Асфальт юлда саздан барган сыман
Кимсетсәләр әгәр күңелне,
Матур хисләреңне сизмәсәләр,
Бу – хурлауга тигез түгелме?

Ләззәт, шатлык теләп атлаганда,
Кире, юньсез фикер йөртсәләр,
Ай-һай авыр, мактау сүзе көтеп,
Сине хурлап, әрләп сүксәләр.

Югарыда җилләр көчле уйный,
Кышын суык түбән урында.
Җаным өши, дуслар борчылсалар

Гел үзләре генә турында.

## ЯЛГЫШЛЫК ЯСАМА

Вакыты юк һич иркәмнең –
Юа керен, идәнен.
Күңел күзе күрми бугай
Карт-корының кирәген.

Кар оча тышта, буран, ди,
Өйдә генә торам, ди.
Күңел ачар чараларны
Башка җирдә корам, ди.

Теләмәсәң, сәбәпләр күп,
Ялган сыя картларга.
Йөрәктәге җылы сүзне
Саклыйлармы ятларга?

Ярар инде, юк имән чөй
Турыларга кыекны.
Йөрәгемне саклау өчен
Кырып ташлыйм мыекны.

Сәбәп сөйләп, юк, кимсетмә,
Мине юләргә санап.
Берүк ялгышлык ясама,
Гел югарыга карап.

## ТӨШЕНМИСЕҢ

Рәнҗесәм, рәнҗешем тотар,
Каһәрләсәм – каһәрем.
Минем йөрәгемә дәва
Исән диган хәбәрең.

Син бит мине үзең керттең
Мәхәббәт дөньясына.
Бүген бирмисең даруын
Җаннарым дәвасына.

Төшенмисең йөрәгемне,
Аңламыйсың күңелне.
Бик үтенәм, таплый күрмә
Чәчәкләнгән гомерне.

Озак кисәң, киемне дә
Киясе килми бугай.
Озак кигән кием сыман,
Син дәме әллә шулай?

Аңламыйм, никтер суындың,
Бик биектән карыйсың.
Әллә минем теләгемне

Гел җүләргә саныйсың.

Таләп итәргә хакым юк,
Сорыйм, көтәм назыңны.
Берүк көзгә әйләндермә
Күңелдәге язымны!

**ТАПЛАМАГЫЗ КҮҢЕЛНЕ**

Саклар идем сине назлар белән,
Күңелеңә сирпеп гүзәллек.
Теләр идем тән һәм телләреңә
Ихлас, ягымлылык – сөярлек.

Мәхәббәттә күңел бик нечкәрә,
Гаделсезлек авыр тоела.
Канатланып күңел чәчәкләре
Гаделсез бер сүздән коела.

Кешеләрнең эчке гүзәллеген
Киметмиме керле якасы?
Ятар урыннарың тапланганда,
Йокларга да килми ятасы.

Бу гадәти, чын күренеш, юкса
Ник борчыйдыр икән күңелне?
Уйламыйча юкка таплыйлар бит
Шатлык белән үтәр гомерне.

**ЯЗГЫ ХИСЛӘР**

Сандугачка җимнәр сиптем,
Тәме калды телемдә.
Татлы исләр, язгы хисләр
Тибрәлделәр тәнемдә.

Яшә әле, сандугачым,
Сайрап тор күңелемдә.
Сине дә назлап саклармын
Үлгәнче гомеремдә.

*** * ***

Бер ананың сөтен имеп үстек,
Бер үк төрле тәндә каныбыз.
Күңелләрдә көчле туганлык бар,
Аерым яшәсә дә җаныбыз.

Саулык телим. Еллар бик тиз чаба,
Сиздермичә гомер узганын.
Горурланып әйтәм, иртәгә дә
Бәхетле бул инде, туганым.

Бәйрәм көнең белән тәбрик итеп,
Йөрәк җылым телим бирергә.
Гомер бәйрәменең күп килгәнен
Насыйп кылсын иде күрергә.

## ТАБИБЛАРГА

Кешеләргә изгелеге булса,
Бар да җаннар лаек догага.
Саулык сакчылары сез – табиблар,
Иң кадерлеләре дөньяда.

Сау кешеләр генә иген игә,
Йортлар, юллар төзи халыкка,
Сезнең кебек изге җаннар гына
Мәңгелеккә калыр тарихта.

## КОДАЧАМА

Тездән түбән озын чәчләреңне
Булдымы соң назлап сыйпаучы?
Булмадымы рухы зәгыйфьләрдән
Йөрәк ашап, күңел кыйнаучы?

Алла сиңа барын биргән иде,
Гүзәллеккә өстәп ягымлык.
Сәбәпләр күп, ачык булмаса да,
Гомер кыскартырлык явызлык.

Язмыштыр шул кайбер ялгышлыкка
Синең гомер туры килүе.
Ошамаган шартлау кисәкләре
Эзләп килеп сиңа тиюе.

## МИНЕМ БАБАЙ

Сиксәннән үтсә дә, бабай
Саклый яшьлек гадәтен.
Тарта тормыш арбасын,
Биреп булган сәләтен.

Дөнья гизгән, күпне күргән –
Яхшысын, яманын да.
Хезмәтен дә, хөрмәтен дә,
Дөресен, ялганын да.

Үз фикерен ныгыткан ул,
Иләп иләктәй барын.
Аклаган хезмәте белән
Нәсел исемен данын.

Җырлый туган ягын мактап,
Гаделлекне яклап.
Гаделсез, явыз җаннарны
Үтә җырында таптап.

Кайберәүләргә ошамый,
Нәфесе туймый, диләр.
Хезмәт, хәрәкәт яшәтә,

Шуны да төшенмиләр.

Омтылып яшәү көн өсти,
Селкенми яшәү хәтәр.
Төкерә кеше сүзенә,
Яшәсә йөзгә кадәр.

## ӘЛЛӘ ДӨРЕСМЕ?

Урман буйларында томан,
Юллары да бик яман.
Адым саен тирән чокыр,
Шәһәр урамы сыман.
Урам юллары төзәлер,
Бүгенгесе бик яман.
Ямау өстендә ямау бит,
Мескен киеме сыман.
Илдә гүзәллекләр арта,
Хәзер бик таламыйлар.
Намус, әдәп белмәгәннәр
Әйткәнне аңламыйлар.
Кайбер авылда эш харап,
Читләшәләр бит җирдән.
Эшләргә бушый алмыйлар
Аракы дигән чирдән.
Җитәкчеләр исеме бар,
Хуҗасы юк авылның.
Сугыш үткән сыман кала
Эзе төссез давылның.
Авылларны талыйлар бит,
Булган байлыкны ватып.
Җитәкче кесә кабарта,
Нигез ташлары сатып.
Нигә бер дә күрмиләр соң
Югарыдагы күзләр?
Әллә дөресме бергә дип
Астан сөйләнгән сүзләр.

## ГҮЗӘЛ КАЛАМ

Гүзәл калам, тормыш арбам минем,
Гүзәллегең белән куанам.
Кайнап торган эчтәлеген сизеп,
Уңышларын күреп юанам.

Һәр кирпечең, һәр кагылган кадак
Яшәр өметемне арттыра.
Хезмәт сөйгән дусларымны күрсәм,
Алга барыр юлым яктыра.

Яраттым сине, гүзәл калам,
Һәр җылыңны сөеп табынам.
Таудан карап Нократ өсләренә,
Яшәү дәрте белән кабынам.

Мамадышым, син чәчәктә бүген,
Тыныч күктә балкый нурларың.
Һәр тармакта йолдыз булып калка
Хезмәт сөйгән батыр улларың.

Яшә, калам, туган, яшәр төбәк,
Бер туганы булып Казанның.
Татарстан уты биек янсын,
Иң яктысы булып заманның.

*** * ***

Гадәтеңне янә яңарттың да
Озак йөрттең мине урамда
Төшендермәк буласыңмы әллә
Мине куеп арткы планга.

Мин төшенәм тиеш урынымны,
Шуңа төртмим алга борынымны.
Юк, көлмә син һәм көлдермә,
Рәнҗетердәй селтәп кулыңны.

Ышандырма ялганыңны кушып,
Борчылырдай урын калдырма.
Күңелемнең матур омтылышын
Читкә атып утта яндырма.

Кешелекнең бәхет елмаюы
Ул гаделлек булып чагыла.
Фикерләрең артык буталганда,
Акылны куш күңел сагына.

## МИН БӘХЕТЛЕ СИНЕ ҮПКӘНГӘ

Ай, йолдызлар безгә шаһит булды,
Кичке җилләр сыйпап үткәндә...
Караңгы төн никтер тиз яктырды,
Беренче кат сине үпкәндә.

Ул көннәрне гөлләр чәчәк атты,
Сандугачлар кунды гөлләргә.
Шул бәхетле көннәр тамыр бирде
Без яшисе алгы көннәргә.

Гомер көзем җимешләргә бик бай,
Үкенмимен гомер үткәнгә.
Мин бәхетле картлык көнемдә дә
Яшьлегемдә сине үпкәнгә.

## ИСКӘ АЛ

Уникесе бүген, уникесе.
Хәтереңне яңарт, кадерлем.
Дога белән җанны сафландырыйк,
Белеп үткән гомер кадерен.
Шөкер итик үткән гомерләргә,
Сазлы чокырлары булса да.

Без бәхетле картлык көнебездә,
Яшьлек давылларда узса да.
Гомер юлы тигез булмый һич тә,
Бик бормалы безнең юллар да.
Мең-мең рәхмәт сиңа
Саклаганга мәхәббәтне озак елларга.
Уникесе иде. Җитәкләшеп,
Безгә кайтып кердек бергәләп.
Мөмкин булса, татлы мизгелләргә
Кайтып килер идем үрмәләп.
Ерак калды, ләкин онытылмый
Безгә бәхет биргән ул таңнар.
Алтмыш өч ел яшәр өчен менә
Берләшкәнгә безнең тән, җаннар.
Гел үбешеп, ансат, җиңел генә
Мөмкин түгел тормыш куарга.
Алла безне парлап яраткандыр
Авырлыкны бергә узарга.
Бергә тарттык авыр йөк арбасын.
Яшәр өчен миңа көч бирдең,
Ятып еласам да, басып җырласам да
(Рәхмәт сиңа!),
Яннарымда, бәгърем, син идең.

**СИКӘЛТӘЛЕ УРТАК ЮЛЛАР**

Мин яшьтән өйләндем. Сабый чактан бергә авыл урамы тузаннарын яланаяк туздырып уйнап үскән, яныннан киткәч тә, күз алдымда йөри торган яраткан кызым Наиләгә. Тыйнак та, төскә-биткә, гәүдәгә дә игътибарны җәлеп итәрдәй кыз иде.

Безнең заманда авыл урамында бала-чага бик күп иде. Аулак өйләргә йөри, кызлар исе керә башлагач та ни өчендер малайларның кызларны кыйнау гадәте бар иде. Мин Наиләгә беркемнән дә кул тидертмәдем. Чын мәгънәсендә дуслар идек. Алай гына түгел, ерак кода белән кодача да идек. Өйләнешү өчен дә Аллаһы Тәгалә үзенең рәхмәте белән көтмәгәндә- уйламаганда мөмкинлек тудырды. Сугыш елы... 16 яшь тулуга, безне солдат иттеләр. Сугыш беткәч, олы яшьтәгеләрне өйләренә җибәрделәр. Ә безне алар урынына, олы, җаваплы урыннарны сакларга билгеләделәр. Мәскәү өлкәсе Ногинск шәһәренә урнашкан хәрби урыннарны сакларга туры килде. Мин – кече командир, постларга солдатларны озатып, смена алыштыручы булып алты ай каравылда йөрдем. Чирләдем. Мәскәү госпиталеннән соң мине, дәваланырга дип, өйгә җибәрделәр. Кайттым. Авыл тынып калган сыман. Наиләм Тула өлкәсенә шахтага эшкә киткән иде. Без хат алышып тордык. Ике арада кабынган матур мәхәббәт сүрелмәде. Язганнары әле дә күңелем түрендә:

Сандугачым, әйтеп сайра,
Кайсы талга кунасың?
Күзем йомсам, күз алдымда
Торган кебек буласың.

Бу хисләрне үзе дә минем мәхәббәт утында янганнар күз алдына китерә аладыр.

Читлекләргә кергән саен,
Үлем төшә исемә.
Әллә сагынганга инде,
Кермисездер төшемә.
Әни миңа «китмә» диде,
Үзем киттем карышып.
Ярты тонна вагон этәм
Кырыена ябышып, –

дип язган җырлары да минем солдат йөрәгемә кереп, аңа булган ярату хисләремне ныгыткан сыман тоела иде. Үзем дә бик сагына идем. Шуңа микән, авылга кайткан көннәрдә үк, Наиләмнең кайтуын сорап хәбәр бирдем. Ул озак көттермәде, кайтты. Аның белән очрашулар авыру солдат өчен тизрәк савыгырга сәбәп булгандыр, бәлки.

Минем эти үлгән, әни авырый, олы апам кияүгә чыккан, әнинең дә, туганнарның да мине өйләндерәселәре килә. Әтинең энесенең хатыны –«чибәр җиңги» (халык артисты Миңгол Галиевнең әнисе) – бик күркәм, безгә бик игътибарлы булып, безнең теләкләрне Наиләмнең әти-әнисенә дә җиткерде. Без өйләнештек. Ул чорда хәзергечә олы туйлар ясау мөмкинлеге юк иде. Кияү булып бабайларга менеп ике кич кундырдылар. Өскә сугышта үлгән җизнинең матур күлмәген кидерделәр. Шулай итеп мин гаиләле булдым.

Алда язганымча, мин өйгә дәваланырга гына җибәрелгән идем. Ел үтүгә, кызыбыз туды. Әмма кызымны туйганчы сөяргә вакыт булмады, мине яңадан армия сафларына чакырдылар. Ульяновск шәһәренә офицерларның белемен күтәрү буенча курс штабына җибәрделәр. Башта – отделение командиры, аннары экспедитор булдым. Хезмәтем җайлы. Вакыт иркен. Яздым да яздым хатларны. Безнең курс белән янәшә генә хәрби училище бар иде. Миңа шунда укырга тәкъдим иттеләр. Минем күңелдә авылым, Наиләм, кызым. Рәхмәт әйтеп, укудан баш тарттым. Бераздан отпускага җибәрделәр. Кайттым, авылда хәл бик авыр. Кунакка кайткан солдатны ашатырга бәрәңге таба алмыйлар... Мин янә солдат хезмәтемдә Сызрань шәһәрендәге хәрби училищега укырга кердем. Бу турыда өйдә белмәделәр дә. Хатлар язарга да вакыт азайды. Сугыш беткәндә, мин һава десантында хезмәт итә идем. Училищены тәмамлагач, Белоруссия хәрби округындагы Бобруйск шәһәренә взвод командиры булып киттем. Беренче кабул итеп алган солдатлар минем яшьтәшләрем – җиде ел хезмәт иткән солдатлар булды. Ярышта без беренче урынга чыктык, мине кул сәгате белән бүләкләделәр. Полктан снайперлар төркеме төзеп, мине төркем җитәкчесе итеп билгеләделәр. Аннан мине Минск шәһәренә укырга җибәрделәр. Гаиләмне сагынам, янга алу мөмкинлеге юк. Политмәктәптән янә үзем хезмәт иткән частька кайттым. Мине артиллерия ротасына политхезмәткәр ярдәмчесе итеп билгеләделәр. Шуннан соң марксизм-ленинизм университетына укырга кердем. Хезмәт гөрли. Фатирда яһүд милләтеннән булган бик мәгънәле, игътибарлы кешеләрдә тордым. Бервакыт фатир хуҗалары мине өйләнергә кыстый башладылар. Мин эштән кайтуга, өйләренә бик чибәр яһүд кызын чакырганнар. Минем күз алдымда авылым, Наиләм... Бу турыда часть командирына сөйләп, гаиләмне алып килергә мөмкинлек бирүләрен сорадым. Мәсьәлә уңай хәл ителде. Шәһәрнең икенче кырыенда фатир алып, гаиләмне алып килдем. Бобруйск шәһәрендә улыбыз туды. Без бик бәхетле гаилә булып яшәгәндә, дивизия штабына, генералга чакырдылар да Мәскәүгә хәрби политидарәгә барырга куштылар. Анда мине Кореяга җибәрүләре турында әйттеләр (бу турыда беркемгә дә әйтергә ярамый иде). Гаиләмне авылга кайтарып куйдым. 26 декабрь көнне хезмәт урынында идем. Мине тагын генерал чакыртты. Ул, гаилә хәлегезне исәпкә алып, сезне көнчыгышка түгел, көнбатышка җибәрергә күрсәтмә булды, диде. Ул елларда ике балалы офицерлар тыныч елларны сугышка ярамый дигән күрсәтмә булган булса кирәк.

Мине төньяк хәрби округка җибәрделәр. Штаб Германиянең Польшага кушылган Легница шәһәрендә. Мине, авыр танк, үзйөрешле артиллерия частеннан килгәнгәдер, техникаларны яхшы белә дип, төркемнең үзәк аерым автомобиль батальонына политхезмәткәр итеп билгеләделәр. Алга барасы яктылык сүнде. Университетта уку бетте. Күңел һаман туган якта... Бер-бер артлы югарыга язган хатлар да файда бирми. Менә, ниһаять, генерал чакыртты. «Нәрсә булды?» – ди. Мин туган илгә кайтасы килүемне җиткердем. Шуннан соң мине янә үзем хезмәт иткән Белоруссиягә Бобруйск шәһәренә җибәрделәр. Бик яхшы каршы алдылар. Мин, рухланып, эшкә керештем. Гаиләмне алып килдем. Без тагын бәхетле идек. Тик... янәдән политбүлеккә чакырдылар. Анда көтелмәгән авыр хәбәр: Мәскәүдәге хәрби җитәкчеләр чит илдән чыгарга рөхсәт биргән язуга «запаска» дип кул куйганнар. Сәясәт бүлеге начальнигы: «Бездә армиядән чыгарга тиешле кешеләр күп, ләкин ул син түгел, без, синең эшеңне яңадан карап, бу ялгышны төзәтәчәкбез», – диде һәм шунда ук партия өлкә комитеты җитәкчеләре белән телефоннан сөйләште. Мине инструктор итеп алырга булдылар. Мин үзем белән бергә хезмәт итүче офицерлар белән сөйләштем. Алар күбесе: «Син нәрсә, гражданскийда тамагыңны туйдырырлык эш таба алмам диеп куркасыңмы әллә?» – дип киңәш иттеләр. Нәрсә уйларга да белгән юк... Авылга кайтырга да уңайсызланам... Озак уйлап тормадым, гаилә белән Урта Азиягә юл тоттым. Сәмәрканд шәһәренең 10 нчы номерлы урта мәктәбенә эшкә урнаштым. Монда да тормыш авыр. Шулай да тырышам, яшәргә кирәк. Җәйгә җиңел промышленностьның өлкә буенча оештырылган пионер лагерена җитәкче итеп билгеләделәр. Бераздан мине янә Сәмәркандка тауга – картада да күренмәгән бер урынга – партия бюросы секретаре итеп җибәрделәр. Бардым. Шахталар... Берничә генә йорт, контора, бараклар. Бу минем өчен сөрген сыман иде. Ике-өч көн шунда яшәдем, әмма эшне кабул итмәдем, кайтып киттем. Икенче елны өлкә комитеты карары белән, районнарны партия кадрлары белән ныгытырга дип, Метан районына җибәрделәр. Әмма без күченеп йөреп бик арыган идек инде. Киңәшләштек тә гаиләбез белән туган авылга кайтып киттек. Бу вакытта инде безнең гаиләдә алты җан иде: дүрт бала, Наиләм һәм мин. Кесәдә акча юк. Туган җирдә дә барысы да без уйлаганча ук түгел. Бик көтеп тормаганнар. Эш юк. Менә мин урман хуҗалыгына, такта яру заводына мастер булып урнаштым. Тырышам, көн күрердәй эш кебек. Ниһаять, без йортлы булдык. Эштән курыкмадым. Авыл халкыннан сөт тә җыйдым, кибеттә сатучы да булдым, сельпода да эшләдем, клуб эшләрен оештырган чак та булды. Кайда эшләсәм дә, эшләрем гел уңай барды. Мәдәният министрлыгы Галимнәр йортында безнең клуб эше турында фотокүргәзмә ясап, гыйльми конференция үткәргәндә, чыгыш ясарга да туры килде. Партия обкомы пленумында идеология мәсьәләсе буенча чыгыш ясагач, беренче секретарь Табиев минем адреска мактау сүзләре әйтте. Шул елны мине ТАССР Верховный Советының Мактау грамотасы белән бүләкләделәр. Бу мине республика күләмендә тану иде. Шул көннән соң мин авыл советы рәисе, партоешма секретаре, колхоз рәисе, нефтебаза директоры булып эшләдем. 70 яшькә җиткәнче эшләп, пенсиягә чыктым. Пенсиягә чыккач та тик ятмадым. Эшмәкәр дә идем, җәмәгатьчелек эше белән дә районда халык театрында баш рольләрне башкаручы артист та, районыбызның Аксакаллар шурасы рәисе, республикада аксакаллар президиумы әгъзасы да булдым. Район Татар иҗтимагый үзәгендә рәис булып тордым, концертларда чыгышлар ясадым, кайда эшләсәм дә, рәсемем район Почет тактасында булды. Шулай итеп гомер үтте. Мин – Бөек Ватан сугышы ветераны, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Шәйхи Маннур исемендәге премия лауреаты, Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы, Татарстан журналистлар берлеге әгъзасы, шәһәребезнең мактаулы гражданины. Ун китабым дөнья күрде. Наиләм белән тугыз бала үстердем: бишесе табиблык хезмәтендә, икесе укытучы, икесе бухгалтер-экономист белеме белән эшлиләр. Гомеремнең изге эзе булып калсын дип, туган авылыма Аллаһ йорты – мәчет салдырттым. Зиратны тимер челтәр белән чолгап алдым. Уңышларымның барысы өчен дә да Наиләмә бурычлымын дип уйлыйм. Ул мине хезмәткә дә, яшәргә дә рухландыручы булып яшәде. Рәхмәтем чиксез аңа.

**ШӨКЕР**
Гел үбешеп кенә яшәп булмый,
Мактанырдай мизгел аз түгел.
Саф мәхәббәт белән сугарылган
Гел көрәштә узды бу гомер.

Сабый чаклар бар да күз алдымда,
Тузан ерган чаклар урамда.
Яшәү өчен җәен арба тарттык,
Кышын – чана салкын буранда.

Без бәхетле картлык көнебездә,
Үттек җиңеп тормыш давылын.
Безне кочып, хөрмәт итеп яши
Торган шәһәр, туган авылым.

Мәхәббәт ул бетми картайгач та,
Йоклап булмый бергә ятмасаң.
Пешкән аш та йөрәгеңә ятмый,
Бергә утырып бергә капмасаң.

Диңгез дулкыннары чайкагандай,
Күп чайкады безне язмышлар.
Көзен килгән язга бездән шөкер,
Кылынса да кайбер ялгышлар.

Безнең язлар кире килмәс инде,
Тулып аксалар да инешләр.
Гомер көзе, табигатьтә кебек,
Шөкер,
Бик мул итеп бирде җимешләр.

ЭЧТӘЛЕК
Көзләрдә дә язлар кабатлана. *Л.Фаршатова*

Яшәү яме синең белән
Күңел сиңа тартыла
Гомерем мизгелләре
Сөйгәнемә
Су сибүче син инде
Сөю – бәхет ул
Рәхмәт сиңа
Мин бәхетле синең белән генә
«Кешеләр бит тәмләп чәй эчәләр...»
Кайт тизрәк
Кайтам
Үзәгендә күңелнең
Яшәү бирсен
Гомер көзендәге яз
Наиләмә
Шатлык гомер өсти кешегә
Зур рәхмәт аңа
Гомер өстәүче
Бүген дә малай
Җиңү сизәм
Кайт син
«Якын дустым, бәйрәм бүләгенә...»
«Бәйрәм миңа син булганда гына...»
Гөлләр чәчик
«Сагындыра үткән яшьлек гомер...»
Эзем калса иде тарихта

Син бит бер генәм
Рәнҗемә
Син үзең
Үстек димиләр
Оныттың
Сагынам
Минем теләк
Мизгелләр бар
Эзлим әле
Тик син генә
«Таң алдыннан уянам мин...»
«Яшьлекне юләр дисәк тә...»
Яңа елга өмет
Бәлки
«И бер Аллам, шатлык, куаныч бир...»
Нык тот, акыл
Аңлаша торган түгел
Ирләр бурычы
Ачкычы бит үз кулыңда
Киңәш
Хурга калма
«Сусап үткән яшьлек елларымда...»
Дару яса
Уйларга кирәк
«Картая һәм туза тәннәр...»
Көрәш, курыкма!
Кабул булсын теләкләр
Шикләнү
Сагай
«Сагыш эзләгәндәй ерак киттем...»
Сүнмәс кояш
«Күңел нечкә, юктан хәтер кала...»
«Күршедә бәлеш ашыйлар...»
«Хәерле юл теләп дога кылам...»
Борчылмагыз
Гаепләмим
Рәнҗедем
Төшенмисең
Гомерем дәвамы
Изгелекләр теләп
Көтәм
Кайт яныма
Насыйп булсын
Чәчкәләрең сакла
Шуны телик
Барын уйлап
Мин сагынам
Насыйп итсә иде
Күлмәк бул син
«Кеше белми кеше хәлләрен...»
Шифаханәдә
«Калсын гомерем эзләре»
Хатын-кызларга
Язмыштыр
«Хөрмәтне кармалап булмый...»
«Рәхмәт, игътибар бирүче...»
Йолдызлар сүнмиләр
Мамадышым – туган ягым
«Изгелекләр теләп тәбрик итәм...»
Кызганыч
Чиләк кирәк
Вакыт ала барын
«Декабристлар бер дә теләмәгән...»
Үкенечләр калмасын
«Дусларны чәйгә чакырдым...»
Хәйрия елы
Мамадышым
Ялгыштым
Табигать хатасымы

«Нигә рәхәт икән яннарыңда...»
«Үзе юкта яман уйлар туа...»
Үтә гомер ничек булса да
Рәнҗетмә
Кил син яннарыма
Рәхмәт сиңа
Нигә килдең?
Канатларым тигез
Җүләр, димә
Нигә?
Юк, туймадым
Гаделсезлек турында
Сихерләндем, ахры
Бәхет белән үтсен көнебез
Көннәр өстим
«Сыер савам, тирес ерам...»
Горурлану
«Мин бәхетле – янып сөя беләм...»
«Нигә «кәттәкәнгә» бардым йомыш белән...»
Ялгыш язмыш
«Сиксән ул туксан түгел, кыерсытма...»
Аңлыйк барын
«Горурланып әйтәм...»
Кем гаепләр?
Өмете барның гомере бар
Көчләр табылыр
«Үткәннәрем әкият түгел минем...»
Акылсызлар
Онытма
Изге эзләр
Сорап түгел
Син генә уйларымда
Сине эзли
Бәлки
Сөбханалла!
«Күңелем шат, рәхмәт сиңа...»
«Язлар күмә җирне гүзәллеккә...»
Дәү әнием!
Шаһинур Мостафинга
Сүрелмәсен
Картайдым әле
Син булганда гына
Пешмәгәннәр турында
Ышан син
Уйланулар
Яшим догада
Әмма шулай
Шул чагында
Өзелмәсен тамырлар
Булган чакта сәләтең
Әллә шунда туып үскәнгә
Бәхетле газап турында
Йөрәкләрне саклыйк ярадан
Килсен язлар
Һәркемгә назлар кирәк
Күңел нечкә
Ярату кирәк
Бәхетле син өзелеп сөйгәндә
Төгәл кирәк
Яратыгыз картларны
Бик кадерле син миңа
«Сез матурлык эзләүче, бирүче...»
«Сезнең заманда да булгандыр ул...»
«Йөрәк елый, күңел сызлый бүген...»
«Үзем юлда, корал кулда...»
Ник килмәдең?
«Артистлар гына кылана...»
Язлар телим
«Теләп алган картаң»

Йөрәктәге теләк
Белеп яшик
Ни хикмәттер
Үзгәрә кирегә
Җанны өшетә
Ялгышлык ясама
Төшенмисең
Тапламагыз күңелне
Язгы хисләр
«Бер ананың сөтен имеп үстек...»
Табибларга
Кодачама
Минем бабай
Әллә дөресме?
Гүзәл калам
«Гадәтеңне янә яңарттың да...»
Мин бәхетле сине үпкәнгә
Искә ал
Сикәлтәле уртак юллар
Шөкер

Литературно-художественное издание

**Галиев** Вахит Валиевич

**РАССВЕТ СЧАСТЬЯ**

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Галиев** Вахит Вәли улы

**БӘХЕТ ТАҢЫМ**

Мөхәррире *Р.Г.Сәлахов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы
*Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.08.2010.
Форматы 70x90 1/32. Шартлы басма табагы 5,27+вкл.0,59
Тиражы 1000 д. Заказ О-1207.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет JaһatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
«Татмедиа» ААҖ филиалы

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.